# ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ

# ҖЫЕЛМА БАСМАСЫ

## № 12

декабрь
1999

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
РӘСМИ БАСМАСЫ
КАЗАН
1999

# ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ҖЫЕЛМА БАСМАСЫ

*№ 12*
*декабрь*
*1999*

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
РӘСМИ БАСМАСЫ
Казан
1999

Лицензия № 174 1996 елның 03.10 бирелде
Җитештерүгә тапшырылды
Формат А5. Оригинал-макеттан басылды
Тиражы 1000 нөсхә. Заказы
Бәясе килешү буенча.
"АБАК" нәшрияты.
420045 Казан, Н.Ершов ур., 31б.
Җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять АБАК-хезмәт күрсәтү үзәгендә басылды
Лицензия № 0080 1997 елның 03.12 бирелде
420107 Казан, Һади Такташ ур., 105

*ЯЗЫЛУ ИНДЕКСЫ 78696*
**ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ҖЫЕЛМА БАСМАСЫ:**
Татарстан Республикасы Дәүләт Советы рәсми басмасы

© Татарстан Республикасы Дәүләт Советы

## Эчтәлек

765. «Татарстан Республикасының акцизлар турындагы аерым бер закон актларының үз көчләрен югалтуларын тану турында» Татарстан Республикасы Законы ....6
766. «1999 елга Татарстан Республикасының бюджет системасы турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына өстәмә кертү турында» Татарстан Республикасы Законы ....7
767. «1999 елга Татарстан Республикасының бюджет системасы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законына өстәмә кертү турында» Татарстан Республикасы Законы ....7
768. «1999 елга Татарстан Республикасының бюджет системасы турында» Татарстан Республикасы Законына өстәмә кертү хакында» Татарстан Республикасы Законы ....8
769. «1999 елга Татарстан Республикасының бюджет системасы турында» Татарстан Республикасы Законы ....8
770. «Эшчәнлекнең аерым бер төрләре өчен йөкләнгән керемгә берләшкән салым турында» Татарстан Республикасы Законы ....63
771. «2000-2005 елларга йогышлы авыруларны вакцина белән профилактикалау» республика максатчыл программасы турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары....87
772. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 1 декабрендәге утырышы көн тәртибе турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары....87
773. «Татарстан Республикасының аерым район, шәһәр судлары судьяларын сайлау һәм рәисләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары....89
774. «Халыкны туберкулездан саклау һәм туберкулезга каршы ярдәм турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары....90
775. «Авыл хуҗалыгы җирләрен залогка салу турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары....91
776. «Гадәттән тыш хәлләрдә иминлек турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары....91
777. «Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлекләрен сату-алу турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары....92
778. «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» Федераль законның 24 статьясына өстәмә кертү хакында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары....93
779. «Җәмәгать тәртибен һәм идарә итү тәртибен бозган өчен административ җаваплылык турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә кертү тәртибе хакында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1993 елның 18 маендагы 1858-XII номерлы карарына үзгәреш кертү турында»

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары ........................ 94
780. «Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы халык депутатларының кагылгысызлыгын тәэмин итү өлешендә Татарстан Республикасы Конституциясенең һәм «Татарстан Республикасы халык депутатларының жирле Советы халык депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законының «Татарстан Республикасы Прокуратурасы тарафыннан үтәлеше хакында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 20 маендагы карары үтәлешенең барышы турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары ........................ 95
781. «Хокук тәртибен тәэмин итүдә Татарстан Республикасы гражданнарының катнашуы турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары ........................ 96
782. «Россия Федерациясенең Федераль Җыелышы Дәүләт Думасының Ветераннар эшләре буенча комитетының, Мәскәү өлкәсе хезмәт ветераннарының, район, Кораллы Көчләр һәм хокук саклау органары ветераннарының җәмәгать оешмаларының Россия Федерациясе Президентына, Россия Федерациясе Федераль Җыелышының Федерация Советы Рәисенә, Россия Федерациясе Федераль Җыелышының Дәүләт Думасы Рәисенә, Россия Федерацисе Хөкүмәте Рәисенә, Россия Федерацисе субьектларының закон чыгару һәм башкарма хакимият органнары житәкчеләренә Россия Федерациясе ветераннарын хокукый һәм социаль яклауга карата дәүләт сәясәтен булдыру турындагы мөрәҗәгате хакында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары.. 97
783. «Автотранспорт чараларын тротуарлар янында парковкалауны тәртиптә салу чаралары турында» Казан шәһәре администрациясе башлыгының 1998 елның 7 сентябрендәге 1801 нче карары хакында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары ........................ 98
784. «Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының төзәтү эшләре һәм социаль реабилитацияләү хезмәте эшчәнлеген камилләштерү чаралары турында» Татарстан Республикасы Президенты Указын гамәлгә ашыруның барышы хакында» Татарстан Республикасы халык депутаты И.С. Абдуллин таләбе турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары........................ 98
785. «Суд яклавына хокукны (Татарстан Республикасы Конституциясенең 33 статьясы) гамәлгә ашыру һәм дәүләт хакимиятен дискредитацияләү турында» Татарстан Республикасы халык депутаты С.К.Осколок таләбе турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары ........................ 99
786. «Татарстан Республикасы Конституциясенең 104 статьясын үтәү турында» Татарстан Республикасы халык депутаты С.К. Осколок таләбе хакында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары ........................ 99
787. «Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча җәзаларны үтәү идарәсенә салым ташламалары бирү турында» Татарстан Республикасы халык депутаты В.Н. Чубаренко таләбе хакында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары ........................ 100
788. «Кече эшкуарлыкка булышлык итү өлешендә Татарстан Республикасы бюджет законнарының үтәлмәве турында» Татарстан Республикасы халык депутаты С.А.Брусов таләбе хакында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары ........................ 100
789. «Татарстан Республикасы кулланучыларын ягулык-энергетика ресурслары белән тәэмин итү чаралары турында» Татарстан Республикасы Дәүләт

Советы карары..........................................................................................................101
790. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме беренче пленар сессиясе «көн тәртибенә өстәмә мәсьәләләр кертү турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары.............................................................................................101
791. Татарстан Республикасы халык депутатлары вәкилләренең киңәшмәсе турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары..........................................................................................................102
792. «Татарстан Республикасы халык депутаты М.Ш.Хөсәеновны Татарстан Республикасы Дәүләт Советында даими нигездә эшләүдән азат итү турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары.............................102
793. «Кулланучыларга кайнар һәм салкын су бирү нормалары һәм тарифлары турында» Татарстан Республикасы халык депутаты Н.Ф.Әбдрәшитова таләбе хакында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары.................103
794. «Татарстан Республикасы гражданнарын дарулар белән тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы халык депутаты Ф.Ш.Сафиуллин таләбе хакында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары.................103
795. «Зеленодол шәһәре эчке эшләр идарәсенең гражданнар мөрәҗәгатьләрен караганда законнарны үтәве турында» Татарстан Республикасы халык депутаты С.К.Осколок таләбе хакында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары ..........................................................................................................104
796. «Гражданнарны хәрби хезмәткә чагыруны Татарстан Республикасы территориясендә туктатып тору турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 15 сентябрендәге карарын үтәүнең барышы хакында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 23 сентябрендәге карарын үтәүнең барышы турында Татарстан Республикасы хәрби комиссары мәгълүматы хакында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары ..........................................................................................................104

**I**

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАБУЛ ИТКӘН ЗАКОННАР ҺӘМ КАРАРЛАР

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 765. Татарстан Республикасының акцизлар турындагы аерым бер закон актларының үз көчләрен югалтуларын тану турында

**1 статья.** Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлеше гамәлгә кертелү белән бәйле рәвештә түбәндәгеләр үз көчләрен югалтты дип танырга:

«Акцизлар турында» Татарстан Республикасының 1993 елның 23 мартындагы 1786-XII номерлы Законы (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993 ел, № 3);

«Акцизлар турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә керту тәртибе хакында» Татарстан Республикасы Югары Советының 1993 елның 23 мартындагы 1787-XII номерлы карары (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993 ел, № 3);

«Акцизлар турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә керту тәртибе хакында» Татарстан Республикасы Югары Советының 1993 елның 23 мартындагы 1787-XII номерлы карарына үзгәрешләр керту турында» Татарстан Республикасы Югары Советының 1993 елның 25 маендагы 1850-XII номерлы карары (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993 ел, № 5).

**2 статья.** Әлеге Законны рәсми басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

**3 статья.** Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты үзенең норматив хокукый актларын әлеге Законга туры китерергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев**

Казан шәһәре,
1999 елның 16 ноябре
№ 2426

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 766. «1999 елга Татарстан Республикасының бюджет системасы турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына өстәмә кертү турында

**1 статья.** «1999 елга Татарстан Республикасының бюджет системасы турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998 ел, №12; 1999 ел, №6, № 9) түбәндәге редакциядә җиденче өлеш өстәргә:

«1999 елның 1 гыйнвареннан Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсенең хуҗалык идарәсен Татарстан Республикасының республика бюджетына күчерелә торган өлешендә өстәлгән бәяләргә салым түләүдән һәм Татарстан Республикасының Юллар фондына салымнардан азат итәргә».

**2 статья.** Әлеге Законны рәсми басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

**Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев**

Казан шәһәре,
1999 елның 16 ноябре
№ 2427

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 767. «1999 елга Татарстан Республикасының бюджет системасы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законына өстәмә кертү турында

**1 статья.** «1999 елга Татарстан Республикасының бюджет системасы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законына өстәмә кертү турында» Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999 ел, № 6) түбәндәге өстәмәне кертергә:

1 статьяның 6 пунктының икенче абзацын «сәнәга оешмаларының» дигән сүзләрдән соң «,төзелеш комплексының һәм торак-коммуналь хуҗалыкның» дигән сүзләр белән тулыландырырга.

**2 статья.** Әлеге Законны басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

**Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев**

Казан шәһәре,
1999 елның 16 ноябре
№ 2428

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 768. «1999 елга Татарстан Республикасының бюджет системасы турында» Татарстан Республикасы Законына өстәмә кертү хакында

**1 статья.** «1999 елга Татарстан Республикасының бюджет системасы турында» Татарстан Республикасының 1998 елның 22 декабрендәге Законының 12 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998 ел, №12; 1999 ел, №6, №9) түбәндәге редакциядә сигезенче өлеш өстәргә:

«Иректән мәхрүм итү рәвешендә җинаять җәзаларын үтәүче учреждениеләрне, шулай ук Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Җәза үтәтү идарәсе предприятиеләрен һәм оешмаларын 1999 елның 1 гыйнвареннан Татарстан Республикасының республика бюджетына күчерелә торган өлешендә өстәлгән бәяләргә салым түләүдән һәм Татарстан Республикасында Юллар фондына, Татарстан Республикасының Экология фондына салымнардан һәм башка түләүләрдән азат итәргә».

**2 статья.** Әлеге Законны рәсми басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

**Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев**

Казан шәһәре,
1999 елның 16 ноябре
№ 2429

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 769. 2000 елга Татарстан Республикасының бюджет системасы турында

**1 статья.** 2000 елга Татарстан Республикасының республика бюджетын керемнәр буенча - 18823675 мең сум күләмендә һәм чыгымнар буенча 19635544 мең сум күләмендә расларга.

2000 елга Татарстан Республикасының республика бюджеты кытлыгының иң чик күләмен 811869 мең сум күләмендә билгеләргә.

2 **статья.** 2000 елга Татарстан Республикасының республика бюджеты керемнәре акцизлар, өстәлгән бәягә салымның бер өлеше, предприятиеләр һәм оешмалар табышына салымның бер өлеше, физик затлардан керем салымының бер өлеше, сатудан салымның бер өлеше, табигый байлыклардан файдаланган өчен түләүләрнең бер өлеше, уен бизнесына салымның бер өлеше, башка салым түләүләре һәм җыемнары, максатчыл бюджет фондлары акчалары исәбеннән барлыкка килә, дип билгеләргә.

3 **статья.** 1999 елда гамәлдә булган җир өчен салым һәм аренда түләве ставкалары 2000 елда җирләрнең барлык категорияләре өчен 1,2 коэффициенты белән кулланыла, дип билгеләргә.

4 **статья.** Тамырдан җибәрелүче агач өчен түләүнең 1999 елда гамәлдә булган минималь ставкалары 2000 елда 1,2 коэффициенты белән кулланыла, дип билгеләргә.

5 **статья.** 2000 елда нефтькә акциз ставкаларын һәм Татарстан Республикасының нефть чыгаручы компанияләре буенча Татарстан Республикасының республика бюджетына акча күчерү нормативларын түбәндәге күләмнәрдә билгеләргә:

| | 1 тонна өчен акциз ставкасы | Татарстан Республикасының республика бюджетына акча күчерү нормативы |
|---|---|---|
| Бөтен нефть чыгаручы компанияләр буенча | 65 сум 34 тиен | 50 сум 34 тиен |

1 тонна өчен 15 сум ставкасы буенча акциз Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Бюджеттан тыш дәүләт торак фондына күчерелә.

6 **статья.** 2000 елга файдалы казылмалар чыгарган өчен түләү ставкаларын чыгарылган ресурсны реализацияләү бәясеннән (өстәлгән бәягә салымнан һәм акцизлардан гайре) түбәндәге процентларда билгеләргә:

| **Файдалы казылмаларның (чималның) төрләре** | **Ставка** |
|---|---|
| 1. Нефть һәм газ | 6 |
| 2. Табигый битум | 4 |
| 3. Гипс ташы | 4 |
| 4. Фосфоритлар | 4 |

| | |
|---|---|
| 5. Цемент чималы | 4 |
| 6. Туфракны известьлау өчен карбонат токымнары | 3 |
| 7. Карбонат токымнары | 3 |
| 8. Киселгән таш | 3 |
| 9. Бут һәм вак таш өчен төзелеш ташы | 3 |
| 10. Ком-гравий катнашмасы | 4 |
| 11. Пыяла һәм формалау комы | 4 |
| 12. Төзелеш комы | 3 |
| 13. Бентонит балчыклары | 4 |
| 14. Керамзит балчыклары | 4 |
| 15. Кирпеч балчыклары | 2,5 |
| 16. Глауконитлар, цеолитлар | 4 |
| 17. Торф, торфовивианит | 3 |
| 18. Җир асты сулары | 6 |
| 19. Файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләү (күрсәтелүче хезмәтләрнең хакыннан чыгып) | 2 |

2000 елга җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләүләр бюджетларның дәрәҗәләре буенча түбәндәгечә бүленә, дип билгеләргә (процентларда):

| | Түләүләрнең төрләре | Бюджетлар буенча бүленеш | |
|---|---|---|---|
| | | республика | районнар һәм шәһәрләр |
| 1. | Файдалы казылмаларны чыгарган өчен түләү | | |
| | - торф, сапропель, җир асты сулары һәм шифалы сулар буенча; | – | 100 |
| | - гомумтаралган файдалы казылмалар буенча; | – | 100 |
| | - нефть, газ, Идел һәм Кама елгалары үзәннәреннән чыгарылучы ком-вак таш катнашмасы, табигый битум, гипс ташы, цемент чималы буенча; | 70 | 30 |
| | - файдалы казылмаларның калган төрләре (фосфоритлар, бетонит балчыклары, керамзит балчыклары, төзелеш известе өчен карбонат токымнары, киселгән таш, пыяла һәм формалау комы, глауконитлар, цеолитлар) буенча | – | 100 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2. | Файдалы казылмаларны лицензиядә билгеләнгән лимитлардан (квоталардан) артыграк кулланган өчен түләү 5 мәртәбәгә арттырылган ставка буенча алына; | 60 | 30 |
| | - нормативлардан тыш кулланылыш билгеләгән орган счетына - 10 процент | | |
| 3. | Файдалы казылмаларны чыгаруга бәйле булмаган җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләү | 50 | 50 |

**7 статья.** Предприятиеләрнең, оешмаларның һәм чит ил юридик затларының мөлкәтенә салым ставкасын салым салу базасының 2 проценты күләмендә билгеләргә.

«КамАЗ» ачык акционерлык җәмгыятенең һәм аның оешмаларының мөлкәтенә салым ставкасын Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан расланган исемлек буенча салым салу базасының 0,5 проценты күләмендә билгеләргә.

Квартал саен ясала торган иң соңгы исәп-хисап буенча һәр айның 5 ендә бюджетка түләнергә тиешле салым суммасының 1/3 е күләмендә предприятиеләр һәм оешмалар мөлкәтенә салым буенча аванс түләүләре кертергә. Салым түләүнең квартал сроклары бозылган очракта, билгеләнгән тәртиптә пеня исәпләп барырга.

2000 елда физик затларның корылмаларына, биналарына һәм төзелмәләренә салым ставкасын, мөлкәтнең суммар инвентаризациясе хакыннан чыгып, түбәндәге күләмнәрдә билгеләргә:

| Мөлкәтнең суммар инвентаризациясе хакы | Салым ставкасы |
|---|---|
| 500 мең сумга кадәр | 0,1 процент |
| 501 мең сумнан 1000 мең сумга кадәр | 0,3 процент |
| 1001 мең сумнан 1500 мең сумга кадәр | 0,5 процент |
| 1500 мең сумнан артканда | 1,5 процент |

**8 статья.** Реинвестицияләүгә җибәрүне исәпкә алып, дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштырудан килгән акчалар төрле дәрәҗәләрдәге бюджетлар һәм хосусыйлаштыру фондлары арасында түбәндәге нормативлар буенча бүленә:

а) Татарстан Республикасының Хосусыйлаштыру фонды һәм

Татарстан Республикасы бюджеты арасында:

(процентларда)

| | Татарстан Республикасының Хосусыйлаштыру фондына | Татарстан Республикасы бюжетына |
|---|---|---|
| Хосусыйлаштырудан алынган акчаларның гомуми суммасы | 50 | 50 |

б) төрле дәрәҗәләрдәге бюджетлар арасында:

*(процентларда)*

| Объектларны хосусыйлаштырудан | Татарстан Республикасының республика бюджетына | Җирле бюджетларга |
|---|---|---|
| Республика милкендәге | 100 | |
| Коммуналь милектәге | | 100 |

**9 статья.** Предприятиеләрнең һәм оешмаларның табышына (кеременә) Татарстан Республикасы бюджетына кертелүче салым ставкасын түбәндәгечә билгеләргә:

а) предприятиеләр, оешмалар һәм чит илләрнең юридик затлары өчен - 19 процент күләмендә;

б) арадашчы гамәлләреннән, алыш-биреш итүләрдән, биржалардан, брокер конторaларыннан, банклардан, башка кредит һәм иминият оешмаларыннан алынган предприятиеләр табышы өчен - 27 процент күләмендә.

Өстәлгән бәягә салымны Татарстан Республикасы бюджетына күчерү 50 процент нормативы буенча башкарыла, дип билгеләргә. Керем салымы Татарстан Республикасы бюджетына күчерелә, моңа Россия Федерациясе белән Татарстан Республикасы арасында үзара бюджет мөнәсәбәтләре турында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы хөкүмәтләре арасындагы килешү нигезендә федераль бюджетка тапшырылучы билгеләнгән ставканың 1 проценты керми.

**10 статья.** Татарстан Республикасының нефть чыгаручы компанияләрен өстәмә нефть чыгарырга кызыксындыру максатларында:

1. Рентабельсез, аз дебитлы скважиналардан чыгарылган нефтьне реализацияләүнең 5180 мең тонна күләменә:

- Минерал ресурслар запасларын торгызу һәм файдалы

казылмалар чыгаруның нәтиҗәлелеген арттыру фондына акча күчерүләрнең ставкасын (өстәлгән бәягә салымнан һәм акциздан гайре) реализацияләү бәясеннән 5,5 процент күләмендә билгеләргә;

- зыянга эшләүче, аз дебитлы һәм күп сулы скважиналардан нефть чыгаруны тәэмин итүче скважиналарны һәм төп фондларны Татарстан Республикасының республика бюджетына күчерелә торган өлешендә предприятиеләр мөлкәтенә салым түләүдән азат итәргә.

2. Нефть бирүчәнлекне арттыруның яңа (гидродинамик, физик-химик, җылылык, газ, геологик-физик һәм микробиологик) алымнарын куллану исәбенә чыгарылган нефтьне реализацияләүнең 3750 мең тонна күләмен:

- җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләүдән һәм Татарстан Республикасының Минерал ресурслар запасларын торгызу һәм файдалы казылмалар чыгаруның нәтиҗәлелеген арттыру фондына акча кертүләрдән азат итәргә.

3. Яңа ятмалардан нефть чыгарылу исәбенә нефтьне реализацияләүнең 1765 мең тонна күләмен:

- җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләүдән, Татарстан Республикасының Минерал ресурслар запасларын торгызу һәм файдалы казылмалар чыгаруның нәтиҗәлелеген арттыру фондына акча кертүләрдән азат итәргә.

Углеводородларның җиңел фракцияләрен тотып калу исәбенә «Татех» ябык акционерлык җәмгыяте чыгарган нефтьнең 62 мең тонна күләмен:

- җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләүдән һәм Татарстан Республикасының Минерал ресурслар запасларын торгызу һәм файдалы казылмалар чыгаруның нәтиҗәлелеген арттыру фондына акча кертүләрдән азат итәргә.

Нефть шламнарын эшкәртү исәбенә «Татойлгаз» ябык акционер җәмгыять чыгарган нефтьнең 20 мең тонна күләмен:

- җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләүдән һәм Татарстан Республикасының Минерал ресурслар запасларын торгызу һәм файдалы казылмалар чыгаруның нәтиҗәлелеген арттыру фондына акча кертүләрдән азат итәргә.

Нефть компанияләре әлеге статьяда каралган ташламалы өстенлекләрдән файдалану исәбенә, алган акчаларын Татарстан Республикасының нефть тармагын үстерүгә җибәрергә тиеш.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты нефть чыгару йөкләмәсен билгеләргә һәм нефтьне реализацияләү квоталарын нефть чыгаручы компанияләр буенча бүлеп бирергә тиеш.

**11 статья.** «Алабуга җиңел автомобильләр заводы» җитештерү берләшмәсенә («АлАЗ» ҖБ), шулай ук «Алабуга» ирекле икътисадый зонасында башка катнашучыларга «Алабуга» ирекле икътисадый зонасы турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясы нигезендә салым ташламалары бирергә.

**12 статья.** «КамАЗ» ачык акционерлык җәмгыятенә һәм аның предприятиеләренә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслаган исемлек буенча Татарстан Республикасының максатчыл бюджет фондларына түләүләр буенча (мәҗбүри медицина иминләштерүенә һәм Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин итү дәүләт фондына түләүләрдән гайре) инвестиция салым кредиты бирергә.

**13 статья.** 2000 елга Татарстан Республикасының республика бюджетын барлыкка китергәндә исәпкә алынган фараз күрсәткечләрдән артыграк җитештерелгән продукция (башкарылган эшләр, күрсәтелгән хезмәтләр) составындагы өстәлгән бәягә кертелгән күләмгә карата алынган табышка салымның Татарстан Республикасының республика бюджетына күчерелә торган өлешендә салым түләүдән 2000 елда сәнәга предприятиеләре һәм башка товар җитештерүчеләр азат ителәләр, дип билгеләргә.

Югарыда күрсәтелгән предприятиеләргә һәм оешмаларга ташламалы өстенлекләр агымдагы түләүләрне тулысынча һәм вакытында түләп барган очракта гына бирелә. Агымдагы түләүләрнең срокларын кварталга ике тапкырдан да артыграк бозмаганда һәм шул ук кварталда төшеп калган керемнәрне компен-сацияләгәндә генә ташламалы өстенлек алу хокукы сакланып калырга мөм-кин.

Җирле бюджетларга күчерелүче табышка салым өлешендә шундый ук карарлар кабул итүне дәүләт хакимиятенең җирле органнарына тәкъдим итәргә.

**14 статья.** Сәнәга предприятиеләре һәм башка товар җитештерүчеләр 2000 елда автомобиль юлларыннан файдаланучыларга салынган салымны түләүдән, 2000 елга Татарстан Республикасының республика бюджетын барлыкка китергәндә исәпкә алынган фараз күрсәткечләрдән артыграк җитештерелгән продукция (башкарылган эшләр, күрсәтелгән хезмәтләр) составындагы өстәлгән бәягә кертелгән күләмгә карата Гомумтармак һәм тармакара фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләренең республика фондына (НИОКР фондына) түләүләрдән азат ителә, дип билгеләргә.

Югарыда күрсәтелгән предприятиеләргә һәм оешмаларга

ташламалы өстенлекләр агымдагы түләүләрне тулысынча һәм вакытында түләп барган очракта гына бирелә. Агымдагы түләүләрнең срокларын кварталга ике тапкырдан да артыграк бозмаганда һәм шушы ук кварталда төшеп калган керемнәрне компенсацияләгәндә генә ташламалы өстенлек алу хокукы сакланып калырга мөмкин.

Ташламалы өстенлекләр бирү нәтиҗәсендә калган акчаларны предприятиеләр һәм оешмалар билгеләнгән тәртиптә расланган бизнес-планнарда каралган гамәлләрне финанслауга җибәрәләр.

**15 статья.** «Татнефть» ачык акционер җәмгыяте һәм «КамАЗ» ачык акционер җәмгыяте өчен комплектлаучы әйберләр җитештерүче предприятиеләрне, калган акчаларны «Татнефть» ачык акционер җәмгыяте һәм «КамАЗ» ачык акционер җәмгыяте белән кооперацияне үстерүгә җибәргәндә һәм продукциянең исәбен аерым-аерым алып барганда, «Татнефть» ачык акционер җәмгыятенә һәм «КамАЗ» ачык акционер җәмгыятенә поставкалар күләмендә Татарстан Республикасының республика бюджетына күчерелүче өлешеннән өстәлгән бәягә салымның бер өлешен түләүдән азат итәргә.

**16 статья.** Җиңел сәнәга предприятиеләрен, максатчыл бюджет фондларын да кертеп (мәҗбүри медицина иминләштерүенә һәм Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин итү дәүләт фондына түләүләрдән гайре), Татарстан Республикасының республика бюджетына керүче салымнар һәм җыемнар (өстәлгән бәягә салымнан гайре) түләүдән азат итәргә.

Җирле бюджетларга күчерелүче салымнарга һәм җыемнар өлешендә шундый ук карарлар кабул итүне дәүләт хакимиятенең җирле органнарына тәкъдим итәргә.

**17 статья.** Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, предприятиеләрнең һәм оешмаларның салымнар, җыемнар һәм хисаплап барылган пенялар, шулай ук салым законнарын бозган өчен салынган штрафлар буенча 2000 елның 1 апреленә Татарстан Республикасының республика бюджетына түләнергә тиешле бурычларын, түләүне бер елга кичектереп тору һәм алга таба салымнар һәм җыемнар буенча бурычларны өч ел дәвамында түләтеп бетертү юлы белән, мәҗбүри медицина иминләштерүенә һәм Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин итү дәүләт фондына түләүләрдән гайре, максатчыл бюджет фондларын да кертеп, күрсәтелгән бурычларны реструктурлаштырырга тиеш.

Әлеге статьяның шарты шундый ук шартларда 1999 елда Татарстан Республикасының республика бюджеты алдындагы бурычларын реструктуралаштыру турында үзләренә карата карар

кабул ителгән предприятиеләргә һәм оешмаларга кагылмый.

Югарыда күрсәтелгән предприятиеләргә һәм оешмаларга бурычларын түләүне кичектерү һәм бурычларын өлешләп түләтү өчен бирелгән барлык чор дәвамында аларның агымдагы түләүләрне вакытында һәм тулысынча кертүләре шарт. Шул ук кварталда төшеп калган керемнәрне компенсацияләү шартларында һәм агымдагы түләүләрнең срогын кварталга ике тапкырдан да күбрәк бозмаган очракта да, реструктурлаштыру хокукы сакланып калырга мөмкин.

Бурычлар түләүне кичектереп торуны бирү шартлары үтәлгәндә, пенялар һәм штрафлар буенча 2000 елның 1 апреленә җыелган бурычларның дүрттән бер өлеше ел саен гамәлдән чыгарыла һәм киләсе елда пенялар һәм штрафлар буенча калган бурычларны түләтеп бетертү өчен кичектерүнең соңгы елында ул бурычларны тулысынча гамәлдән чыгарганга кадәр бурычларны түләү тагын кичектерелә.

Кичектереп торылган һәм түләү чоры тагын да озайтылган түләүләрне реструктурлаштырганда мондый түләүләрнең суммасы өчен елына биш процент күләмендә түләү алына.

Җирле бюджетларга күчерелүче салымнарга һәм җыемнарга кагылышлы шундый ук карарлар кабул итүне дәүләт хакимиятенең җирле органнарына тәкъдим итәргә.

**18 статья.** Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты:

халык куллану товарларының яңаларын җитештерүне оештыру һәм гамәлдәгеләрен җитештерүне киңәйтү буенча предприятиеләрнең хупланган бизнес-проектларына инвестиция салымы кредитлары бүлеп бирергә;

бизнес-проектларны үтәгәндә бирелгән инвестиция кредитлары суммасын акционер җәмгыятьләренең устав капиталына дәүләт милке өлеше буларак тапшырырга.

**19 статья.** 2000 елга Татарстан Республикасының республика бюджетына түбәндәге бюджеттан тыш максатчыл фондлар акчаларын тупларга (кертергә):

Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин итү фонды

«Янгын куркынычсызлыгы» махсус счеты

Татарстан Республикасының ЭЭМ Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсенең Юл хәрәкәте иминлеге фонды

Татарстан Республикасында Юллар фонды

Татарстан Республикасының Экология фонды

Татарстан Республикасының Хосусыйлаштыру фонды

Гомумтармак һәм тармакара фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә - конструкторлык эшләренең (НИОКР) республика фонды

Татарстан Республикасының Минерал ресурслар запасларын торгызу һәм файдалы казылмалар чыгаруның нәтиҗәлелеген арттыру фонды

Мәҗбүри медицина иминләштерүе

**20 статья.** 2000 елга Татарстан Республикасының республика бюджетына төп чыганаклар буенча керемнәрнең килерен түбәндәге суммаларда исәпләргә:

*(мең сумнарда)*

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Салым керемнәре - барлыгы,<br>шул исәптән: | 8946488 |
| | – предприятиеләр һәм оешмалар табышына (керемнәренә) салым | 1187119 |
| | – физик затлардан керем салымы | 167826 |
| | – өстәлгән бәягә салым | 2823744 |
| | – акцизлар | 2575000 |
| | – сатудан салым | 280000 |
| | – предприятиеләр мөлкәтенә салым | 345795 |
| | – табигый байлыклардан файдаланган өчен түләүләр | 1260000 |
| | – җир салымы һәм җир өчен аренда хакы | 261200 |
| | – чит илләр акчаларын һәм чит ил валютасында белдерелгән түләү документларын сатып алган өчен салым | 12740 |
| | - башка салымнар, җыемнар һәм пошлиналар | 33064 |
| 2. | Салым булмаган керемнәр - барлыгы,<br>шул исәптән: | 1133100 |
| | – дәүләт милкендәге мөлкәттән яки эшчәнлектән килгән керемнәр | 63000 |
| | – кире кайтару шарты белән бирелгән акчаларның килере | 430000 |
| | – салым булмаган башка керемнәр, штрафлар, зыянны түләттерү | 640100 |
| 3. | Бюджеттан тыш максатчыл фондлар керемнәре - барлыгы,<br>шул исәптән: | 8744087 |
| | Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин | |

| | | |
|---|---|---|
| | итү фонды | 301000 |
| | «Янгын куркынычсызлыгы» махсус счеты | 90000 |
| | Татарстан Республикасының ЭЭМ ЮХИДИ идарәсенең Юл хәрәкәте иминлеге фонды | 125148 |
| | Татарстан Республикасында Юллар фонды | 3229118 |
| | Татарстан Республикасының Экология фонды | 325000 |
| | Татарстан Республикасының Хосусыйлаштыру фонды | 100539 |
| | Гомумтармак һәм тармакара фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләре (НИОКР) фонды | 175000 |
| | Татарстан Республикасының Минерал ресурслар запасларын торгызу һәм файдалы казылмалар чыгаруның нәтиҗәлелеген арттыру фонды | 3127138 |
| | Мәҗбүри медицина иминләштерүе | 1271144 |

**21 статья.** 2000 елда Татарстан Республикасы дәүләт бурычының иң югары чиген 10 900 000 мең сум күләмендә, дип билгеләргә, шул исәптән:

- Татарстан Республикасының эчке дәүләт бурычының иң югары чиген - 7200000 мең сум күләмендә;

- Татарстан Республикасының тышкы дәүләт бурычының иң югары чиген 3700000 мең сум эквиваленты күләмендә.

**22 статья.** 2000 елда районнарның һәм шәһәрләрнең бюджетларына түбәндәге салымнарны тапшырырга:

- предприятиеләрнең һәм оешмаларның табышына (керемнә) салым - салым салынучы табыштан 19 процент күләмендә, түбәндәгеләрдән гайре:

Азнакай районына һәм шәһәренә - 3 процент, Әлмәт районына һәм шәһәренә - 1,6 процент, Баулы районына һәм шәһәренә - 9 процент, Бөгелмә районына һәм шәһәренә - 8 процент, Зәй районына һәм шәһәренә - 11 процент, Лениногорск районына һәм шәһәренә - 3 процент, Нурлат районына һәм шәһәренә - 17 процент, Сарман районына - 2 процент, Түбән Кама районына һәм шәһәренә - 5 процент.

Арадашчылык гамәлләреннән һәм алыш-биреш итүләрдән, биржалардан, брокер контораларыннан, банклардан, башка кредит һәм иминләштерү оешмаларыннан алынган табышка салымны, видеосалоннар эшчәнлегеннән, язмалар язылган чыганаклар һәм алардагы язмалар прокатыннан керемгә салымнарны салым салына торган табыштан 19 процентлы ставка өчен билгеләнгән нормативларга пропорциональ нисбәттә бүләргә;

- физик затлардан Татарстан Республикасы бюджетына күчерелә торган керем салымы, түбәндәгеләрдән гайре:

Азнакай районына һәм шәһәренә - 70 процент, Сарман районына - 25 процент, Әлмәт районына һәм шәһәренә - 40 процент, Зәй районына һәм шәһәренә - 95 процент;

- предприятиеләрнең һәм оешмаларның мөлкәтенә салым, 100 процент күләмендә, түбәндәгеләрдән гайре:

Азнакай районына һәм шәһәренә - 41 процент, Әлмәт районына һәм шәһәренә - 12 процент, Баулы районына һәм шәһәренә - 90 процент, Бөгелмә районына һәм шәһәренә - 93 процент, Зәй районына һәм шәһәренә - 44 процент, Нурлат районына һәм шәһәренә - 67 процент, Сарман районына - 13 процент, Түбән Кама районына һәм шәһәренә - 88 процент;

- Казан шәһәре бюджетына - Казан шәһәре территориясендә житештерелгән товарларга (күрсәтелгән хезмәтләргә һәм башкарылган эшләргә) өстәлгән бәягә салымның 17 проценты, шул исәптән Казан шәһәре территориясендә 230000 мең сум күләмендә капиталь салуларны финанслау өчен 15 проценты;

- Яр Чаллы шәһәре бюджетына - Яр Чаллы шәһәре территориясендә җитештерелгән товарларга (күрсәтелгән хезмәтләргә һәм башкарылган эшләргә) өстәлгән бәядән салымның 35 проценты.

Уен бизнесына салына торган, Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле салым суммасы Татарстан Республикасының республика бюджеты һәм Татарстан Республикасы шәһәрләре һәм районнары бюджетлары арасында 50 шәр процент күләмендә бүленә.

**23 статья.** 2000 елга үз бюджетларын барлыкка китергәндә, физик затлардан үз территорияләрендә җыелучы мөлкәткә салымның бер өлешен, физик затлардан керем салымының бер өлешен, җир өчен салымның бер өлешен җирле үзидарә органнары күз алдында торган чыгымнарны каплау өчен җитәрлек күләмнәрдә җирле үзидарә бюджетларына тапшыруны халык депутатларының җирле Советларына тәкъдим итәргә.

Югарыда күрсәтелгән чыганаклардан керүче акчалар суммасы минималь социаль стандартлардан һәм нормалардан азрак булса, үз бюджетларында җирле үзидарә органнарына дотацияләр һәм субвенцияләр карауны халык депутатларының җирле Советларына тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасының бюджет системасына күчерелә торган салымнар һәм җыемнар 2000 елның 1 гыйнвареннан башлап Татарстан Республикасы Финанслар министрлыгының Казначылык департаменты тарафыннан Татарстан Республикасының республика

бюджеты һәм Татарстан Республикасы шәһәрләренең һәм районнарының бюджетлары арасында бүленә, дип билгеләргә.

**24 статья.** 2000 елга Татарстан Республикасының республика бюджетында агымдагы чыгымнарны финанслау өчен ассигнованиеләрнең гомуми күләмен 13 454 273 мең сум күләмендә билгеләргә һәм бюджет чыгымнары функциональ классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча боларны түбәндәге суммаларда җибәрергә:

*(мең сумнарда)*

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Дәүләт хакимиятенә һәм идарәсенә, шул исәптән: | 381619 |
| | - дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнары эшчәнлегенә | 62716 |
| | - дәүләт хакимиятенең башкарма органнары эшчәнлегенә | 312803 |
| | - гомумдәүләт идарәсенең башка чыгымнарына | 6100 |
| 2. | Суд хакимиятенә, | 12591 |
| | шул исәптән:<br>– Татарстан Республикасы Югары арбитраж судына | 11096 |
| | – Татарстан Республикасы Конституция судына (Татарстан Республикасы Конституция судын сайлаганчы Татарстан Республикасы Конституция күзәтчелеге комитетын финанслау чыгымнарын саклап калырга) | 611 |
| 3. | Халыкара эшчәнлеккә | 30410 |
| 4. | Хокук саклау эшчәнлегенә | 499300 |
| 5. | Сәнәгага, энергетикага, төзелешкә, шул исәптән: | 34969 |
| | – ягулык-энергетика комплексына | 27969 |
| | – төзелешкә, архитектурага | 7000 |
| 6. | Авыл хуҗалыгына, шул исәптән: | 1610414 |
| | - авыл хуҗалыгы җитештерүенә,<br>шулардан ветеринариягә | 1208000<br>80000 |
| | - җир ресурсларына, | 261200 |
| | шулардан җирләрне тамырдан яхшыртуга | 200000 |
| | - авыл хуҗалыгы өлкәсендәге башка гамәлләргә | 141214 |
| 7. | Әйләнә-тирә мохитне, табигый байлыкларны | |

| | | |
|---|---|---|
| | саклаута, гидрометеоро-логиягә, картографиягә һәм геодезиягә, шул исәптән: | 121000 |
| | - урман ресурсларына | 100000 |
| | -гидрометеорологиягә | 1000 |
| | - әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге башка чыгымнарга | 20000 |
| 8. | Транспортка, шул исәптән: | 263392 |
| | - автомобиль транспортына | 180884 |
| | - тимер юл транспортына | 54777 |
| | - һава юлы транспортына | 10967 |
| | - су транспортына | 16764 |
| 9. | Торак-коммуналь хуҗалыгына, шул исәптән: | 355603 |
| | - торак хуҗалыгына (торак фондын һәм социаль-мәдәни өлкәгә караган объектларны кабул итүне һәм файдалануга тапшыруны кертеп) | 153000 |
| | шулардан: | |
| | «Татэнерго» җитештерү-эксплуатация җәмгыяте тарафыннан шәһәр һәм авыл торак пунктларының энергетика объектларын кабул итеп алу чараларына | 50000 |
| | - коммуналь хуҗалыкка | 188130 |
| | - коммуналь хуҗалыкның башка структураларына | 14473 |
| 10. | Гадәттән тыш вәзгыятьләрне һәм табигый бәла-казаларны кисәтүгә һәм бетерүгә, шул исәптән: | 21000 |
| | - гадәттән тыш вәзгыятьләрне кисәтүгә һәм бетерүгә | 4000 |
| | - граждан оборонасына | 17000 |
| 11. | Мәгарифкә, шул исәптән: | 247872 |
| | - гомуми белем бирүгә | 37293 |
| | - башлангыч һөнәри белем бирүгә | 4000 |
| | - урта һөнәри белем бирүгә | 80483 |
| | - кадрларны яңа һөнәргә өйрәтүгә һәм квалификациясен арттыруга | 43061 |
| | - югары һөнәри белем бирүгә | 26125 |
| | шул исәптән Татар дәүләт милли ниверситетын ачу өчен | 8725 |
| | - мәгариф өлкәсендәге башка чыгымнарга | 56910 |

| | | |
|---|---|---|
| 12. | Мәдәнияткә, сәнгатькә һәм кинематографиягә, шул исәптән: | 232473 |
| | - мәдәнияткә һәм сәнгатькә | 210829 |
| | - кинематографиягә | 18320 |
| | - мәдәният һәм сәнгать өлкәсендәге башка гамәлләргә | 3324 |
| 13. | Массакүләм мәгълүмат чараларына: шул исәптән: | 104326 |
| | -телевидениегә һәм радиотапшыруларга | 50000 |
| | - көндәлек матбугатка һәм нәшриятларга | 49146 |
| | - башка массакүләм мәгълүмат чараларына | 5180 |
| 14. | Сәламәтлек саклауга һәм физик культурага, шул исәптән: | 1029371 |
| | - сәламәтлек саклауга | 835774 |
| | - санитария-эпидемиология күзәтчелегенә | 77597 |
| | - физик культурага һәм спортка, шул исәптән: | 116000 |
| | - балалар һәм яшүсмерләр арасында физкультура-спорт эшен үстерүгә | 50000 |
| 15. | Социаль сәясәткә, шул исәптән: | 568759 |
| | - социаль тәэминат учреждениеләренә | 129922 |
| | - социаль ярдәмгә | 122504 |
| | - яшьләр сәясәтенә | 10000 |
| | - социаль сәясәт өлкәсендәге башка гамәлләргә | 306333 |
| 16. | Дәүләт бурычына хезмәт күрсәтүгә | 777510 |
| 17. | Дәүләт запасларын һәм резервларын тулыландыруга | 50000 |
| 18. | Башка дәрәҗәләрдәге бюджетларга финанс ярдәме күрсәтүгә, шулардан: | 1608249 |
| | -районнар һәм шәһәрләр бюджетларына дотациягә | 476149 |
| | - бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хисапланган өстәмәләре белән хезмәт хакы түләү өчен районнарның һәм шәһәрләрнең бюджетларына субвенцияләргә | 1132100 |
| 19. | Башка чыгымнарга, | 612803 |
| | шул исәптән: | |
| | - Татарстан Республикасы Министрлар | |

| | | |
|---|---|---|
| | Кабинетының резерв фондына | 75000 |
| | - азык-төлек товарлары буенча дәүләт заказын барлыкка китерү өчен кайтарып бирү нигезендә товар кредитына | 400000 |
| | - Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының махсус бүлекчәләрен тотуга һәм матди-техник яктан тәэмин итүгә, салым постларын тотуга һәм спирт сәнәгасе буенча лаборатор контрольне башкаруга | 35244 |
| | - башка чыгымнарга | 102559 |
| 20. | Максатчыл бюджет фондлары чыгымнары - барлыгы, шул исәптән: | 4892612 |
| | - Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин итү дәүләт фонды | 285895 |
| | - «Янгын куркынычсызлыгы» | 53700 |
| | махсус счеты | |
| | - Татарстан ЭЭМ Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсенең Юл хәрәкәте иминлеге фонды | 101116 |
| | - Татарстан Республикасында Юллар фонды | 2060818 |
| | - Татарстан Республикасының Экология фонды | 105160 |
| | - Татарстан Республикасының Хосусыйлаштыру фонды | 31241 |
| | - Гомумтармак һәм тармакара фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләренең (НИОКР) республика фонды | 31900 |
| | - Татарстан Республикасының Минерал ресурслар запасларын торгызу һәм файдалы казылмалар чыгаруның нәтиҗәлелеген арттыру фонды | 951638 |
| | - Мәҗбүри медицина иминләштерүе | 1271144 |

**25 статья.** Продукция өчен вакытында түләнмәгәндә, дәүләт заказчылары хуплаган килеш төзелгән шартнамәләр буенча дәүләт заказын үтәүче предприятиеләрнең һәм оешмаларның түләү сәләте булмау аркасында барлыкка килгән һәм Татарстан Республикасының республика бюджетына, максатчыл бюджет фондларына недоимка суммасына пенялар исәпләмәскә.

**26 статья.** 2000 елга авыл хуҗалыгы өчен бюджет акчаларын бүлүне әлеге Законның 1 нче кушымтасы нигезендә

2089214 мең сум күләмендә расларга.

**27 статья.** 2000 елга Республика инвестиция программасы нигезендә үсеш бюджетын финанслау өчен (әлеге Законның 2 нче кушымтасы) 2000 елга Татарстан Республикасының республика бюджетында 6 181 271 мең сум күләмендә ассигнованиеләр билгеләргә, шулардан:

*(мең сумнарда)*

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Фундаменталь тикшеренүләр һәм фәнни-техник прогресска ярдәм итү | 32600 |
| 2. | Әйләнә-тирә табигать мохитен һәм табигый байлыкларны саклау | 10000 |
| 3. | Авыл хуҗалыгы (техник яңарыш фонды) | 620000 |
| 4. | Максатчыл программаларны гамәлгә ашыруга, шул исәптән: | 72340 |
| | – «Татарстан балалары» республика программасын | 10000 |
| | – «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» Татарстан Республикасы Законын | 7200 |
| | – 1999-2001 елларга Татарстан Республикасында наркотик чараларны явыз ният белән куллануга һәм аларның законсыз әйләнешенә каршы гамәлләрнең комплекслы республика программасын | 55140 |
| 5. | Сәнәга өчен лизинг фонды | 275000 |
| 6. | Спирт сәнәгасен үстерүгә | 259756 |
| 7. | Дәүләт капитал салулары, | 520000 |
| | монннан тыш, Казан шәһәре бюджеты исәбенә дәүләт капитал салулары - 230000 | |
| 8. | Газлаштыру программасын гамәлгә ашыруга | 515100 |
| 9. | Кече эшкуарлыкка ярдәм итүгә (кайтарып бирү нигезендә) | 25000 |
| 10. | Максатчыл бюджет фондлары чыгымнары - барлыгы, шул исәптән: | 3851475 |
| | – Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин итү дәүләт фонды | 15105 |
| | – «Янгын куркынычсызлыгы» махсус счеты | 36300 |
| | – Татарстан Республикасы ЭЭМ ЮХИДИ идарәсенең Юл хәрәкәте иминлеге фонды | 24032 |
| | - Татарстан Республикасында Юллар фонды | 1168300 |
| | - Татарстан Республикасының Экология фонды | 219840 |

| | | |
|---|---|---|
| | – Татарстан Республикасының Хосусыйлаштыру фонды | 69298 |
| | – Гомумтармак һәм тармакара фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләренең (НИОКР) республика фонды | 143100 |
| | – Татарстан Республикасының Минерал ресурслар запасларын торгызу һәм файдалы казылмалар чыгаруның нәтиҗәлелеген арттыру фонды | 2175500 |
| | Моннан тыш: | |
| | – Татарстан Республикасында тузган торакны бетерү комплекслы программасын гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Бюджеттан тыш дәүләт торак фондының бюджетка тупланмаган акчалары | 1759200 |
| | Инвестиция проектларын финанслауга дәүләт гарантияләре | 300000 |
| | Инвестиция проектларын гамәлгә ашыруда салым өстенлекләре | 220000 |

**28 статья.** 2000 елда дәүләт хакимиятен гамәлгә ашыру чыгымнарын 381619 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән:

*(мең сумнарда)*

| Түбәндәгеләрнең эшчәнлеген финанслау чыгымнары: | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Президентының, Президент Аппаратының | 30280 |
| Татарстан Республикасы Дәүләт Советының, аның Аппаратының, даими эшләүче Татарстан Республикасы халык депутатларының | 27050 |
| Татарстан Республикасы халык депутатларына депутат вәкаләтләрен башкаруга бәйле чыгымнарны түләргә | 546 |
| Закон проектларын әзерләү һәм аларга экспертиза ясауга бәйле чыгымнар | 1000 |
| Татарстан Республикасы Дәүләт Советы сессияләрен үткәрүгә бәйле чыгымнар | 2000 |
| Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Парламент контроле комитеты | 1840 |
| Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты | 20234 |
| Татарстан Республикасы министрлыклары, дәүләт комитетлары, ведомстволары һәм аларның органнары | 274969 |
| Татарстан Республикасы халык депутатларын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе | 1900 |

| | |
|---|---|
| Архив учреждениеләрен финанслау чыгымнары | 6100 |
| «Дәүләт хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чыгымнары | 14000 |
| «Татарстан Республикасы алдында аерым казанышлары булган гражданнарга дәүләт пенсиясенә өстәмә түләү турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чыгымнары | 1700 |

**29 статья.** Чыгымнарны 30410 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән:

Россия Федерациясе субъектларында Татарстан Республикасы вәкиллекләрен тоту өчен 2000 елга чыгымнарны 9768 мең сум күләмендә, шул исәптән:

*(мең сумнарда)*

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасының Россия Федерациясендәге вәкаләтле вәкиллеген | 8051 |
| Татарстан Республикасының Свердлов өлкәсендәге даими вәкиллеген | 787 |
| Татарстан Республикасының Санкт-Петербург шәһәрендәге һәм Ленинград өлкәсендәге даими вәкиллеген | 930 |

Татарстан Республикасының халыкара эшчәнлеген башкару өчен 2000 елга чыгымнарны 20642 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән:

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасының Үзбәкстан Республикасындагы даими вәкиллегенә | 990 |
| Татарстан Республикасының Азербайҗан Республикасындагы даими вәкиллегенә | 833 |
| Татарстан Республикасының Казагыстан Республикасындагы вәкаләтле вәкиллегенә | 941 |
| Татарстан Республикасының Франциядәге вәкаләтле вәкиллегенә | 5632 |
| Татарстан Республикасының Төркиядәге вәкаләтле вәкиллегенә | 3542 |
| Татарстан Республикасының Вашингтон шәһәрендәге (АКШ) даими вәкиллегенә | 4637 |
| Татарстан Республикасының Чехия һәм Словакия Республикаларындагы даими вәкиленә | 2307 |
| Татарстан Республикасының Кипр Республикасындагы вәкиллегенә | 1760 |

**30 статья.** Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 2000 елда дәүләт хезмәткәрләренең һәм бюджет өлкәсендә эш-

ләүчеләрнең санын арттыруга китерүче карарлар кабул итүгә хокуксыз.

**31 статья.** 2000 елда Татарстан Республикасының дәүләт хезмәткәрләрен тоту чыгымнарын экономияләү максатында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасында дәүләт хезмәткәрләренең чик санын раслауны да кертеп, Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары структурасын камилләштерү чараларын күрергә.

**32 статья.** Бюджетта каралган гамәлләрне эзлекле финанслауны тәэмин итү йөзеннән, 2000 елда Татарстан Республикасының республика бюджетыннан районнар һәм шәһәрләр бюджетларына 1608249 мең сум күләмендә дотацияләр һәм субвенцияләр бүлеп бирергә, шул исәптән:

*(мең сумнарда)*

| | Дотация | Субвенция |
|---|---|---|
| Аксубай районы | 12905 | 34070 |
| Актаныш районы | 17067 | 34150 |
| Алабуга районы | 30686 | 56800 |
| Алексеевск районы | 17399 | 34555 |
| Апас районы | 14429 | 25340 |
| Арча районы | 9682 | 48300 |
| Әгерҗе районы | 7930 | 34350 |
| Әлки районы | 17101 | 29460 |
| Әтнә районы | 11380 | 18210 |
| Балтач районы | 21582 | 37730 |
| Балык Бистәсе районы | 21049 | 34400 |
| Биек Тау районы | 8319 | 16400 |
| Буа районы | 12446 | 42800 |
| Зеленодол районы | 9786 | 38700 |
| Кайбыч районы | 9188 | 16200 |
| Кама Тамагы районы | 12096 | 22300 |
| Кукмара районы | 31543 | 53550 |
| Лаеш районы | 7154 | 30900 |
| Мамадыш районы | 24635 | 55800 |
| Менделеев районы | 4700 | 17800 |
| Минзәлә районы | 16395 | 31660 |
| Мөслим районы | 11658 | 27300 |
| Питрәч районы | 20540 | 29430 |
| Саба районы | 11889 | 27300 |
| Спас районы | 16874 | 35200 |

| | | |
|---|---|---|
| Тәтеш районы | 10681 | 39030 |
| Тукай районы | 5186 | 6300 |
| Теләче районы | 7757 | 22346 |
| Чирмешән районы | 3074 | 18870 |
| Чистай районы | 13988 | 33710 |
| Чүпрәле районы | 11575 | 29300 |
| Югары Ослан районы | 12373 | 22200 |
| Ютазы районы | 5389 | 3580 |
| Яңа Чишмә районы | 1900 | 9000 |
| Зеленодол шәһәре | 14857 | 70600 |
| Чистай шәһәре | 10936 | 44459 |
| Барлыгы: | 476149 | 1132100 |

Дотация Татарстан Республикасы республика бюджетының керем өлеше фактта ничек үтәлүен исәпкә алып бүленә.

Татарстан Республикасының республика бюджетыннан субвенция, бюджет өлкәсендә эшләүчеләрнең өстәмәләре белән хезмәт хакын өлешчә түләү өчен бирелә һәм катгый рәвештә әлеге максатларда гына файдаланыла.

**33 статья.** Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин итү дәүләт фондына 2000 елга иминләштерү кертеме ставкасын, милек рәвешләренә карамастан, предприятиеләр, оешмалар, учреждениеләр һәм башка хуҗалык итүче субъектлар өчен, хезмәт өчен түләүнең һәръяклап исәпләнелгән суммасына карата 1,5 процент күләмендә билгеләргә.

Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин итү дәүләт фондының 2000 елга бюджетын керемнәр буенча 301000 мең сум, чыгымнар буенча 301000 мең сум күләмендә расларга.

2000 елда Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин итү дәүләт фондының керемнәре түбәндәге чыганаклар исәбеннән барлыкка килә:

*(мең сумнарда)*

| | |
|---|---|
| Мәҗбүри иминләштерү кертемнәре түләүләре | 275200 |
| Башка төрле акча керүләр | 25800 |

2000 елда Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин итү дәүләт фонды акчалары түбәндәге максатларга җибәрелә:

*(мең сумнарда)*

| | |
|---|---|
| Эшсезлек буенча пособиеләр түләүгә, | 181525 |
| шул исәптән социаль яклау өчен түләүләргә | 7800 |

| | |
|---|---|
| Эшсезләрне һәм эш белән мәшгуль булмаган гражданнарны һөнәри өйрәтүгә | 17000 |
| Эшсез һәм эш белән мәшгуль булмаган гражданнар өчен җәмәгать эшләрен финанслауга | 5000 |
| Халыкны эш белән вакытлыча тәэмин итүне финанслауга - барлыгы, шул исәптән: | 11600 |
| - балигъ булмаган гражданнарны эш белән тәэмин итү өчен вакытлы эш урыннары булдыруга | 10000 |
| - яшьләрнең эш белән тәэмин ителешен оештыруга («Яшьләр практикасы») | 1600 |
| Инвалидларның хезмәтенә түләү буенча чыгымнарны финанслауга | 800 |
| Вакытыннан алда рәсмиләштерелгән пенсияләрне түләү чыгымнарын кайтаруга | 18800 |
| Эшсезләргә һәм аларның гаилә әгъзаларына матди ярдәм күрсәтүгә | 500 |
| Татарстан Республикасы шәһәрләрендә социаль-эшлекле үзәкләрне финанслауга | 400 |
| Татарстан Республикасы шәһәрләрендә «Эш эзләүчеләр клублары»н, «Яңа старт» җәмгыятьләрен финанслауга | 300 |
| Эшсез гражданнар балаларының ялын финанслауга | 50 |
| Предприятиеләрдә, оешмаларда, учреждениеләрдә хезмәт хакы сакланмаган килеш мәҗбүри ялдагы хезмәткәрләргә компенсация түләүләренә | 9000 |
| Эш белән мәшгуль булмаган, эшсез гражданнар һәм эш бирүчеләр өчен нәшрият һәм мәгълүмат эшчәнлеге чыгымнарына | 1000 |
| Хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү органнарын тотуга | 31500 |
| Хезмәтчәннәр өчен автоматлаштырылган эш урыннары булдыруга | 2105 |
| Хезмәтне саклау гамәлләрен финанслауга | 3230 |
| Заем акчаларына хезмәт күрсәтү чыгымнарына | 1700 |
| Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Бюджеттан тыш дәүләт торак фондына түләүләргә | 3000 |
| Объектлар төзүне инвестицияләүгә (2000 елның 1 гыйнварена җыелган бурычлар исәбеннән) | 10000 |
| Башка чыгымнарга | 3490 |

**34 статья.** Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының Янгынга каршы дәүләт хезмәте идарәсенең «Янгын куркынычсызлыгы» махсус счетына мәҗбүри түләүләр буенча 2000 елга түбәндәге ставкаларны билгеләргә:

янгынга каршы күчмә техникалы янгыннан саклау объект бүлекчәләре булмаган барлык милек рәвешләрендәге предприятиеләрнең, учреждениеләрнең, оешмаларның (бюджет оешмаларыннан

гайре), янгынга каршы дәүләт хезмәтен тоткан өчен тәгәлләнмәгән төзелешнең, чималның, материалларның һәм башка шундый кыйммәтләрнең, үстерүдәге һәм симертүдәге хайваннарның, аз кыйммәтле һәм тиз тузучан предметларның, тәгәлләнмәгән җитештерүдәге чыгымнарның, әзер продукциянең, алып сату товарларының, башка төрле запасларның һәм чыгымнарның төп акчаларыннан калдык суммасының 0,15 проценты күләмендә;

норматив коэффициент буенча түләүләргә төзелеш, капиталь ремонт буенча, объектларны реконструкцияләү, оештыру-хокукый һәм милек рәвешләренә карамастан, предприятиеләрне, биналарны, корылмаларны һәм башка объектларны киңәйтү буенча эшләрнең гомуми смета хакыннан 0,5 процент күләмендә;

иминләштерү оешмалары тарафыннан мәҗбүри түләүләргә янгын куркынычыннан иминләштерү өлешендә мөлкәтне һәм (яисә) граждан җаваплылыгын ихтыярый иминләштерү буенча иминләштерү түләүләре суммасыннан 5 процент күләмендә.

Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының Янгынга каршы дәүләт хезмәте идарәсенең «Янгын куркынычсызлыгы» махсус счетының 2000 елга керемнәрен 90000 мең сум, чыгымнарын 90000 мең сум күләмендә расларга.

2000 елда «Янгын куркынычсызлыгы» махсус счетының керемнәре түбәндәге чыганаклар исәбеннән барлыкка килә:

*(мең сумнарда)*

| | |
|---|---|
| Дифференциацияләнгән түләү | 84600 |
| Төзелеш-монтаж эшләренең гомуми смета хакыннан норматив коэффициент | 4300 |
| Иминләштерү оешмаларының янгынга каршы ихтыярый иминләштерү буенча иминләштерү түләүләре суммасыннан мәҗбүри түләүләр | 1100 |

2000 елда «Янгын куркынычсызлыгы» махсус счеты акчалары түбәндәге максатларга җибәрелә:

*(мең сумнарда)*

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының Янгынга каршы дәүләт хезмәтенең шәһәрләрдәге һәм районнардагы бүлекчәләренә 25% түләүләргә | 12500 |
| Янгын депосы биналарын һәм торак биналарны капиталь төзүгә һәм капиталь ремонтлауга | 5800 |

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Бюджеттан тыш дәүләт торак фонды түләүләренә | 1500 |
| Янгынга каршы автотехника, автотранспорт, янгынга каршы техник кораллар сатып алуга | 29000 |
| Янгынга каршы техниканы, автотранспортны тотуга, ягулык-майлау материаллары, янгынга каршы техник кораллар сатып алуга | 11000 |
| Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының Янгынга каршы дәүләт хезмәтен тотуга | 7937 |
| Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгына түләүләргә | 4500 |
| Татарстан Республикасы Президентының Резерв фондына түләүләргә | 4500 |
| Социаль яклау өчен түләүләргә | 4950 |
| Заем акчаларына хезмәт күрсәтү чыгымнарына | 4500 |
| Шәһәрләргә, районнарга һәм авыл торак пунктларына газ кертү програмасын финанслауга акча түләүләргә | 2000 |
| Башка чыгымнарга | 1813 |

**35 статья.** 2000 елда Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгы ЮХИДИ идарәсенең Юл хәрәкәте иминлеге фондына кертелүче штрафларның күләмнәрен «Юл хәрәкәте кагыйдәләрен, транспорттан файдалану һәм аны саклау, урам-юллар челтәрен һәм хәрәкәтне оештыруның техник чараларын тоту кагыйдәләрен бозган өчен административ җаваплылык турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгы ЮХИДИ идарәсенең Юл хәрәкәте иминлеге фондына автотранспорт чараларына дәүләт техник тикшерүе уздырудан керүче җыемнарның һәм дәүләт теркәү тамгаларын биргән өчен алынган җыемнарның ставкаларын Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан расланган тәртип нигезендә билгеләргә.

2000 елга Юл хәрәкәте иминлеге фонды бюджетын керемнәр буенча 125148 мең сум, чыгымнар буенча 125148 мең сум күләмендә расларга.

2000 елда Юл хәрәкәте иминлеге фондының бюджет керемнәре түбәндәге чыганаклар исәбеннән барлыкка килә:

*(мең сумнарда)*

| | |
|---|---|
| Штрафлар | 62148 |
| Автотранспорт чараларына дәүләт техник тикшерүе уздырудан җыемнар | 45000 |
| Дәүләт теркәү тамгаларын биргән өчен җыемнар | 18000 |

2000 елда Юл хәрәкәте иминлеге фонды акчалары түбәндәге максатларга җибәрелә:

*(мең сумнарда)*

| | |
|---|---|
| Юл хәрәкәте иминлеге фондының шәһәр һәм район бүлекләренә түләүләргә | 24704 |
| Юл хәрәкәте иминлеге гамәлләренә | 24704 |
| Дәүләт техник тикшерүе станциясен үстерү һәм тоту өчен түләүләргә | 35645 |
| Дәүләт теркәү тамгаларын чыгару буенча эксплуатация чыгымнары өчен түләүләргә | 15363 |
| Социаль яклау өчен түләүләргә | 6883 |
| Татарстан Республикасы Президентының Резерв фондына түләүләргә | 6257 |
| Татарстан Республикасы Эчке эшләре министрлыгына түләүләргә | 3107 |
| Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Бюджеттан тыш дәүләт торак фондына түләүләргә | 700 |
| Башка чыгымнарга | 7785 |

**36 статья.** 2000 елга Татарстан Республикасында Юллар фондына (алга таба - Юллар фонды) күчерелүче салымнарның түбәндәге ставкаларын билгеләргә:

милек рәвешләренә, кайсы ведомствога буйсынуларына һәм оештыру-хокукый рәвешләренә карамастан, предприятиеләр, берләшмәләр, оешмалар, учреждениеләр һәм башка хуҗалык субъектлары өчен ягулык-майлау материаллары (автобензин, дизель ягулыгы, майлар, мотор ягулыгы сыйфатында кулланылучы тыгызландырылган һәм сыеклатылган газлар) реализацияләүгә салым (өстәлгән бәяләргә салымнан тыш) ставкасын реализацияләү суммасыннан (акчалата исәпләнгән) 25 процент күләмендә;

автомобиль юлларыннан файдаланучыларга салым ставкасын продукцияне, башкарылучы эшләрне һәм күрсәтелүче хезмәтләрне реализацияләгән суммадан 1,8 процент күләмендә, ә әзерләүче, сәүдә итүче оешмаларның (шул исәптән күпләп сәүдә итүче оешмаларның) һәм тәэмин итүче оешмаларның салым ставкасын

әйләнештәге суммалардан 0,3 процент күләмендә;

транспорт чараларының биләүчеләреннән салым ставкасын «Татарстан Республикасында юллар фонды турында» 1991 елның 26 декабрендәге 1368-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы белән расланган күләмнәрдә;

Татарстан Республикасыннан читтә нефтьне кире кайтарып бирү шарты белән нефть чималы эшкәрткәндә алынган ягулык-майлау материалларын реализацияләүгә салым ставкасын (өстәлгән бәяләргә салымнан гайре) реализацияләүдән алынган сумманың 15 проценты күләмендә;

автотранспорт чаралары сатып алуга салым ставкасы түбәндәге күләмдә билгеләнә:

юридик затлар өчен - сату бәясеннән 5 процент (өстәлгән бәяләргә салымнан һәм акцизлардан тыш);

физик затлар өчен - Татарстан Республикасыннан читтә сатып алынган автотранспорт чараларының сатып алу бәясеннән 3 процент.

2000 елга Юллар фонды бюджетын керемнәр буенча 3229118 мең сум, чыгымнар буенча 3229118 мең сум күләмендә расларга.

2000 елда Юллар фонды бюджетының керемнәре түбәндәге чыганаклар исәбеннән барлыкка килә:

*(мең сумнарда)*

| | |
|---|---|
| Автомобиль юлларыннан файдаланучыларга салым | 2285354 |
| Ягулык-майлау материалларын реализация-ләүгә салым | 579122 |
| Транспорт чаралары биләүчеләреннән салым | 106179 |
| Автотранспорт чаралары сатып алуга салым | 128884 |
| Кире кайтарып бирү шарты белән биреп торылган нефть чималын эшкәрткәндә алынган ягулык-майлау материалларын реализацияләүгә салым | 79579 |
| Башка чыгымнарга | 50000 |

2000 елда Юллар фонды акчалары түбәндәге максатларга җибәрелә:

*(мең сумнарда)*

| | |
|---|---|
| Казан халыкара аэропортын реконструкцияләүгә | 193400 |
| Халыкара аэропортның һава юллары идарәсен реконструкцияләүгә | 63500 |
| Татарстан Республикасы Президентының | |

| | |
|---|---|
| Резерв фондына түләүләргә | 161456 |
| Заем акчаларына хезмәт күрсәтү чыгымнарына | 160000 |
| Гомуми файдалану юлларында юл эшләренә | 1796381 |
| Кама елгасы аша күпер төзелешенә | 600000 |
| Шәһәрләргә, районнарга һәм авыл торак пунктларына газ кертү программасын финанслау өчен түләүләргә | 30000 |
| Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Бюджеттан тыш дәүләт торак фондына түләүләргә | 30000 |
| Социаль яклау өчен түләүләргә | 177601 |
| Башка чыгымнарга | 16780 |

**37 статья.** 2000 елга әйләнә-тирә табигать мохитен пычраткан һәм табигать ресурсларын яңадан торгызган өчен Татарстан Республикасы Экология фондына кертелүче түләү нормативларын һәм ставкаларын норматив хокукый актлар нигезендә билгеләргә.

2000 елга Татарстан Республикасы Экология фонды (алга таба Экология фонды) бюджетын керемнәр буенча 325000 мең сум, чыгымнар буенча 325000 мең сум күләмендә расларга.

2000 елда Экология фонды бюджеты керемнәре түбәндәге чыганаклар исәбеннән барлыкка килә:

*(мең сумнарда)*

| | |
|---|---|
| Табигать мохитен пычраткан өчен түләүләр | 301000 |
| Табигый байлыкларны торгызу өчен түләүләр | 10000 |
| Башка керемнәр | 14000 |

2000 елда Татарстан Республикасы Экология фонды акчалары түбәндәге максатларга җибәрелә:

*(мең сумнарда)*

| | |
|---|---|
| Әйләнә-тирә мохитне саклау буенча максатчыл программаларны гамәлгә ашыруга | 214240 |
| Татарстан Республикасының табигатьне саклау хезмәтләре эшчәнлеген тәэмин итүгә | 48005 |
| Татарстан Республикасы Президентының Резерв фондына түләүләргә | 16250 |
| Районнарга, шәһәрләргә һәм авыл торак пунктларына газ кертү программасын финанслау өчен түләүләргә | 18000 |
| Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Бюджеттан тыш дәүләт торак фондына түләүләргә | 5600 |

| | |
|---|---|
| Социаль яклау өчен түләүләргә,<br>шул исәптән балаларның җәйге ялы (экологик лагерьлар) өчен | 17875<br><br>3000 |
| Башка чыгымнарга | 5030 |

38 **статья.** 2000 елга Татарстан Республикасының Хосусыйлаштыру фонды (алга таба - Хосусыйлаштыру фонды) бюджетын керемнәр буенча 100539 мең сум, чыгымнар буенча 100539 мең сум күләмендә расларга.

2000 елда Хосусыйлаштыру фонды бюджеты керемнәре түбәндәге чыганаклар исәбеннән барлыкка килә:

*(мең сумнарда)*

| | |
|---|---|
| Дәүләт мөлкәтен сатудан кергән керемнәр | 7500 |
| Хезмәт коллективлары сатып алган акцияләрдән килгән керемнәр | 11250 |
| Кыйммәтле кәгазьләр сатудан килгән керемнәр (акцияләрнең дәүләт өлеше) | 15500 |
| Дәүләт мөлкәтен арендага бирүдән килгән керемнәр | 3500 |
| Дәүләт акцияләр пакетына дивидендлардан керемнәр | 25000 |
| Кредитларны кайтару | 37789 |

2000 елда Хосусыйлаштыру фонды акчалары түбәндәге максатларга җибәрелә:

*(мең сумнарда)*

| | |
|---|---|
| Заем акчаларын кайтарып бирү чыгымнарына | 10200 |
| Предприятиеләрне инвестицияләүгә | 69298 |
| Татарстан Республикасы Президентының 1995 елның 7 мартындагы 149 номерлы Указы нигезендә депозитар хезмәт күрсәтүләр өчен түләүләргә | 3000 |
| Коммуналь мөлкәт белән идарә итү комитетлары белән үзара исәп-хисаплар ясауга | 2900 |
| Баланс тотучылар белән исәп-хисаплар ясауга | 2600 |
| Акча кертүчеләр һәм акционерлар хокукларын яклау буенча республика иҗтимагый-дәүләти фондка түләүләргә | 484 |
| Татарстан Республикасы Президентының Резерв фондына түләүләргә | 5027 |
| Социаль яклау өчен түләүләргә | 5530 |
| Башка чыгымнарга | 1500 |

**39 статья.** Гомумтармак һәм тармакара фәнни-тикшеренү

һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләре фондына (алга таба - НИОКР фонды) 2000 елга түләүләр ставкасын реализацияләнгән продукциянең (башкарылган эшләрнең, күрсәтелгән хезмәтләрнең) үзкыйммәтеннән 1,5 процент күләмендә билгеләргә, шул исәптән 1 проценты (үзәкләштерелмәгән өлеше) үз эшләрен гамәлгә ашыру өчен түләүчеләрнең үз карамагында кала, 0,5 проценты НИОКР фондының үзәкләштерелгән өлешенә күчерелә, дип билгеләргә.

2000 елга НИОКР фондының бюджетын керемнәр буенча 175000 мең сум, чыгымнар буенча 175000 мең сум күләмендә расларга.

2000 елда НИОКР фонды бюджеты керемнәре түбәндәге чыганаклар исәбеннән барлыкка килә:

*(мең сумнарда)*

| | |
|---|---|
| Үзәкләштерелгән өлешне барлыкка китерүнең исәп-хисап күләме (түләмнәрнең 0,5 проценты) | 120000 |
| Кредитларны кире кайтару | 55000 |

2000 елда НИОКР фонды акчалары түбәндәге максатларга җибәрелә:

*(мең сумнарда)*

| | |
|---|---|
| Инвестиция программаларын һәм проектларын финанслауга | 105300 |
| Фәнне өстенлекле юнәлешләрдә үстерү буенча дәүләт программасына | 28000 |
| Татарстан Республикасы Президентының Резерв фондына түләүләргә | 6000 |
| НИОКР фондының устав һәм фәнни-оештыру эшчәнлеген финанслауга | 5300 |
| Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Бюджеттан тыш дәүләт торак фондына түләүләргә | 9800 |
| Социаль яклау өчен түләүләргә | 6600 |
| Районнарга, шәһәрләргә һәм авыл торак пунктларына газ кертү программасын финанслауга түләүләргә | 10000 |
| Башка чыгымнарга | 4000 |

**40 статья.** Минерал ресурс запасларын торгызу һәм файдалы казылмалар чыгаруның нәтиҗәлелеген арттыру өчен Татарстан Республикасының Минерал ресурс запасларын торгызу һәм файдалы казылмалар чыгаруның нәтиҗәлелеген арттыру

фондына кертелүче түләүләрнең 2000 елга ставкаларын чыгарылган нефтьнең сату бәясеннән 8 процент күләмендә һәм, җир асты суларын да кертеп, чыгарылган каты файдалы казылмаларны сату бәясеннән 3 процент күләмендә (өстәлгән бәяләргә салымнан һәм акциздан гайре) билгеләргә.

2000 елга Татарстан Республикасының Минерал ресурс запасларын торгызу һәм файдалы казылмалар чыгаруның нәтиҗәлелеген арттыру фонды бюджетын керемнәр буенча 3127138 мең сум, чыгымнар буенча 3127138 мең сум күләмендә расларга.

2000 елда Татарстан Республикасының Минерал ресурс запасларын торгызу һәм файдалы казылмалар чыгаруның нәтиҗәлелеген арттыру фондының бюджет керемнәре түбәндәге чыганаклар исәбеннән барлыкка килә:

*(мең сумнарда)*

| | |
|---|---|
| Минерал-чимал базасын торгызу өчен түләү | 3127138 |

2000 елда Татарстан Республикасы Минерал ресурслар запасларын торгызу һәм файдалы казылмалар чыгаруның нәтиҗәлелеген арттыру фонды акчалары түбәндәге максатларга җибәрелә:

*(мең сумнарда)*

| | |
|---|---|
| Фәнни-тикшеренү эшләнмәләрен һәм геология-разведка эшләрен финанслауга | 2175540 |
| Заем акчаларына хезмәт күрсәтү чыгымнарына | 10000 |
| Татарстан Республикасы Президентының Резерв фондына түләүләргә | 156357 |
| Социаль яклау өчен түләүләргә | 171993 |
| Татарстан Республикасының Геология буенча дәүләт комитетын финанслауга | 1708 |
| Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Бюджеттан тыш дәүләт торак фондына түләүләргә | 53400 |
| Районнарга, шәһәрләргә һәм авыл торак пунктларына газ кертү программасын финанслауга | 40000 |
| Татарстан Республикасының дәүләт бурычына хезмәт күрсәтү чыгымнарына | 500000 |
| Башка чыгымнарга | 18140 |

**41 статья.** 2000 елда мәҗбүри медицина иминләштерүенә кертемнәрнең иминият тарифын:

а) эш бирүчеләр-оешмалар өчен - эшләр башкару һәм хезмәтләр күрсәтү максатында граждани-хокукый характердагы шартнамәләр, шулай ук авторлык шартнамәләре буенча түләүләрне дә кертеп, финанслау чыганакларына бәйсез рәвештә, хезмәткәрләр файдасына һәрьяклап исәпләнелгән акчалата һәм (яки) натуралата түләүләрдән 3,6 процент күләмендә;

б) индивидуаль эшкуарлар, шул исәптән Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче чит ил гражданнары, гражданлыксыз затлар, шулай ук хосусый детективлар, хосусый практика белән шөгыльләнүче нотариуслар, крестьян (фермер) хуҗалыклары өчен - табыш алу өчен сарыф ителгән чыгымнарны чигереп, эшкуарлык яисә башка төрле эшчәнлектән кергән керемнән 3,6 процент күләмендә;

салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы индивидуаль эшкуарлар өчен - патент бәясеннән чыгып билгеләнә торган керемнең 3,6 проценты күләмендә;

Индивидуаль эшкуарлар, шул исәптән Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче чит ил гражданнары, гражданлыксыз затлар, хосусый детективлар, хосусый практика белән шөгыльләнүче нотариуслар, хезмәт шартнамәсе буенча эшкә алучылар яки эшләр башкару һәм хезмәтләр күрсәтү максатында граждани-хокукый характердагы шартнамәләр һәм шулай ук авторлык шартнамәләре буенча түләүчеләр, финанслау чыганакларына бәйсез рәвештә, хезмәткәрләр файдасына һәрьяклап исәпләнелгән акчалата һәм (яки) натуралата түләүләрнең 3,6 проценты күләмендә мәҗбүри медицина иминләштерүенә иминият кертемнәре түлиләр.

Хезмәт шартнамәсе буенча эшкә алучы яки эшләр башкару һәм хезмәтләр күрсәтү максатында граждани-хокукый характердагы шартнамәләр, шулай ук авторлык шартнамәләре буенча акча түләүче крестьян (фермер) хуҗалыклары, финанслау чыганакларына бәйсез рәвештә, хезмәткәрләр файдасына һәрьяклап исәпләнелгән акчалата һәм (яки) натуралата түләүләрнең 3,6 проценты күләмендә мәҗбүри медицина иминләштерүенә иминият кертемнәре түлиләр;

в) адвокатлар өчен - адвокатлар файдасына исәпләнелгән түләүләрнең 3,6 проценты күләмендә;

г) хезмәт шартнамәсе буенча эшкә алучы яки эшләр башкару һәм хезмәтләр күрсәтү максатында граждани-хокукый характердагы шартнамәләр, шулай ук авторлык шартнамәләре буенча акча түләүче гражданнар (физик затлар) өчен - финанслау чыгымнарына бәйсез рәвештә, хезмәткәрләр файдасына һәрьяклап исәпләнелгән акчалата һәм (яки) натуралата түләүләрнең 3,6 проценты күләмендә;

д) эшләмәүче затлар өчен - Россия Федерациясендә билгеләнгән хезмәт өчен түләүнең минималь күләменә карата һәр кешегә 23 процент күләмендә.

Дәүләт хакимиятенең җирле органнарына Татарстан Республикасы шәһәрләренең һәм районнарының 2000 елга бюджетларын барлыкка китергәндә эшләмәүче затларның мәҗбүри медицина иминләштерүе кертемнәре суммасын тулы күләмдә финанс-ланырга тиешле яклanучан агымдагы чыгымнарга кертергә тәкъдим итә-ргә.

2000 елга Татарстан Республикасының мәҗбүри медицина иминләштерүе бюджетын керемнәр буенча 1271144 мең сум, чыгымнар буенча 1271144 мең сум күләмендә расларга.

2000 елда мәҗбүри медицина иминләштерүе акчаларының бюджет керемнәре түбәндәге чыганаклар исәбеннән барлыкка килә:

*(мең сумнарда)*

| | |
|---|---|
| Эшләүчеләр өчен иминлек кертемнәре | 707276 |
| Эшләмәүчеләр өчен бюджеттан акча керүләр | 563868 |

2000 елда мәҗбүри медицина иминләштерүе акчалары түбәндәге максатларга җибәрелә:

*(мең сумнарда)*

| | |
|---|---|
| Медицина хезмәтләре өчен түләү фондына | 1065345 |
| Резерв фондына, барлыгы, | 77268 |
| шул исәптән: | |
| – Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы юлламасы буенча авыруларны Татарстан Республикасыннан читтә дәвалауга | 24000 |
| Кабат иминләштерү фондына | 88928 |
| Мәҗбүри медицина иминләштерүе программалары фондына | 5923 |
| Башка чыгымнарга | 33680 |

**42 статья.** Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасының җирле бюджетларына ревизия ясарга хокуклы.

**43 статья.** Дәүләт идарәсенең җирле органнары гарантиясе (йөкләмәсе) нигезендә кайтарып алу шарты белән Татарстан Республикасының дәүләт идарәсе органнарына, предприятиеләргә һәм оешмаларга Татарстан Республикасының республика бюджетыннан бүлеп бирелгән акчаларны кире кайтару чорларын сак-

ламаган яки аларны тиешле максатларда файдаланмаган өчен:

- дәүләт идарәсенең җирле органнарына барлык төр финанс ярдәме күрсәтү кыскартыла яки туктатыла;

- дәүләт идарәсе җирле органнарының бурычларын каплау максатларында әлеге Законның 24, 27 статьяларында каралган өлешендә һәм әлеге Закон нигезендә Татарстан Республикасы районнары һәм шәһәрләре бюджетларына күчерелергә тиешле Татарстан Республикасы республика бюджетының бүтән акчалары, Татарстан Республикасының республика бюджеты белән районнарның һәм шәһәрләрнең бюджетлары арасында үзара исәп-хисап ясау юлы белән түләттерелә, дип билгеләргә.

Дәүләт идарәсе җирле органнарының кире кайтару шарты белән бүлеп бирелгән акчалары Татарстан Республикасының республика бюджетына кайтарып бирү өчен җитәрлек булмаган очрак-та, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары, бернинди бәхәскә юл калдырмыйча, бурыч суммасын районнар һәм шәһәрләр бюджетлары счетларыннан Татарстан Республикасының республика бюджеты файдасына күчертергә хокуклы.

**44 статья.** Әлеге Законның 27 статьясында дәүләт инвестицияләренә билгеләнгән чыгымнар 2000 елга республика инвестиция программасы нигезендә дәүләт заказчысы исемлеге буенча финанслана, дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 2000 елга Татарстан Республикасының республика бюджетын үтәү барышында 2000 ел өчен расланган күләмнәр чикләрендә дәүләт капитал салулары исәбеннән төзелә торган төзелешләр һәм объектлар буенча Татарстан Республикасы республика бюджетының 2000 елның 1 гыйнварена җыелган бурычларын беренче чиратта түләп бетерүне гамәлгә ашырырга тиеш.

**45 статья.** Төрле дәрәҗәдәге бюджетлар исәбеннән гамәлгә ашыру тәэмин ителә торган бюджет йөкләмәләрен билгеләүче закон актларында чыгымнарны финанслау чыганакларын бюджет системасы дәрәҗәләре буенча чикләү билгеләнә.

Берләштерелгән бюджетны чыгымнарны финанслау чыганагы буларак билгеләү тыела.

**46 статья.** 2000 елга Татарстан Республикасының республика бюджетында финанслау чыганаклары белән тәэмин ителмәгән закон чыгару һәм башка төрле норматив хокукый актлар 2000 елда үтәлергә тиеш түгел.

Закон чыгару һәм башка төрле норматив хокукый актны гамәлгә ашыру бюджетта өлешчә (тулы күләмдә түгел) финанслау чыганаклары белән тәэмин ителгән очракта, мондый норматив

хокукый акт 2000 елга Татарстан Республикасының республика бюджетында, район яки шәһәр бюджетында һәм җирле үзидарә органы бюджетында каралган акчалар чикләрендә гамәлгә ашырыла һәм кулланыла.

2000 елга Татарстан Республикасының республика бюджеты акчалары исәбеннән өстәмә чыгымнарга китерүче, шулай ук аның керем базасын киметүче законнар һәм башка төрле норматив хокукый актлар, бары тик Татарстан Республикасының республика бюджетына өстәмә акчалар кертү өчен тиешле чыганаклар булганда һәм (яки) 2000 елга Татарстан Республикасы республика бюджетының конкрет статьялары буенча чыгымнарны кыскартканда, шулай ук әлеге Законга тиешле үзгәрешләрне керткәндә генә гамәлгә ашырыла һәм кулланыла.

Башкарма хакимиятнең җирле органнарына районнарның, шәһәрләрнең һәм җирле үзидарә органнарының бюджетларын үтәгәндә шундый ук принципларны кулланырга тәкъдим итәргә.

**47 статья.** Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы казначылык счетларындагы бюджет акчаларын түләтү законнарда каралган тәртиптә бары тик суд органнарының башкару кәгазьләре нигезендә генә гамәлгә ашырыла, дип билгеләргә.

Суд органнарының башкару кәгазьләре нигезендә бюджет акчалары алучыларның акчаларын кичерү, әлеге статьяга туры китереп, Татарстан Республикасының күрсәтелгән казначылык органнары акцепты нигезендә казначылык счетларыннан башкарыла.

**48 статья.** Бюджет учреждениеләре һәм оешмалары белән Татарстан Республикасының республика бюджеты акчалары исәбеннән үтәлә торган шартнамәләр төзү, бюджетларның функциональ (бюджет чыгымнарының ведомство классификациясе) һәм икътисадый классификациясе структурасында алар өчен расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

Бюджет учреждениеләренең һәм оешмаларының Татарстан Республикасының республика бюджеты исәбеннән үзләренә билгеләнгәннән ассигнованиеләрне арттырып гамәлгә ашырыла торган шартнамәләреннән килеп чыгучы кабул ителгән йөкләмәләре агымдагы финанс елының Татарстан Республикасы республика бюджеты акчалары исәбеннән түләнергә тиеш түгел.

Татарстан Республикасының республика бюджетыннан финансланучы оешмалар һәм учреждениеләр тарафыннан кабул ителгән Татарстан Республикасының республика бюджеты акчалары исәбеннән үтәлүче йөкләмәләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә теркәлергә тиеш.

**49 статья.** Предприятиеләргә һәм оешмаларга Татарстан

Республикасының республика бюджетына һәм максатчан бюджет фондларына салымнар һәм башка мәҗбүри түләмнәр кертү буенча кичектерүләрнең яисә ул түләүләрне өлешләп кертүләрнең вакыты 2000 нче финанс елы чигеннән артмаска тиеш, әмма бу вакыт алты айдан да узмаска һәм елга бер тапкырдан да артмаска тиеш, дип билгеләргә. Татарстан Республикасының республика бюджеты түләүләре буенча кичектерүләр яки түләүләрне өлешләп кертүләр бары тик җирле бюджетка түләүләр буенча кичектерүләр яисә түләүләрне өлешләп кертүләр рөхсәт ителгән очракта гына карала.

Бюджет акчаларыннан файдаланган өчен Россия Федерациясе Үзәк банкының рефинанслау буенча әлеге процентларны түләү көненә гамәлдәге ставкасының икедән бер күләмендәге процентлар рәвешендә түләү алына.

**50 статья.** Татарстан Республикасы республика бюджетының әйләнештәге касса акчаларын 2001 елның 1 гыйнварена 500000 мең сум күләмендә расларга.

**51 статья.** 2000 елга Татарстан Республикасы республика бюджетының тулы күләмдә финансланырга тиешле яклanучан агымдагы чыгымнарының түбәндәге исемлеген расларга: мәҗбүри медицина һәм социаль иминият кертемнәрен һәм Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин итү дәүләт фондына һәм Россия Федерациясе пенсия фондының Татарстан Республикасы бүлегенә кертемнәрне исәпкә алып, хезмәт хакы; стипендияләр; дәүләт пособиеләре, балаларга пособиеләр түләү һәм укучыларга туклану өчен бирелгән дотация, халыкка башка социаль һәм компенсация түләүләре; иҗат хезмәткәрләренә гонорарлар, туклану; медикаментлар һәм бәйләү чаралары сатып алу; җирле бюджетларга тапшырыла торган субвенцияләр; энергия ресурслары өчен түләү.

**52 статья.** Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына һәм Татарстан Республикасы Милли банкына 2000 елда Татарстан Республикасының республика бюджеты һәм җирле бюджетлары чыгымнарын һәм керемнәрен исәпкә алу системасын, аларның үтәлешен оештыруны һәм аларның нәтиҗәле эшчәнлеген тәэмин итәргә.

2000 елда Татарстан Республикасының республика бюджеты һәм җирле бюджетларының үтәлешен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты, аның территория бүлекләре гамәлгә ашыра.

Бюджетларның касса үтәлеше гамәлләре, комиссион түләүләр алынмыйча гына, Татарстан Республикасының Милли банкы, «Ак Барс» банкы һәм вәкаләтле башка банклар тарафыннан гамәлгә ашырыла.

**53 статья.** Татарстан Республикасы республика бюджетының аерым бер бүлекләре буенча 2000 елда җитәрлек дәрәҗәдә финансламау, бары тик 2000 елга Татарстан Республикасы республика бюджетының әлеге Законның 24, 27 статьяларында билгеләнгән ассигнованиеләре исәбеннән һәм шул чикләрдә генә компенсацияләнә.

**54 статья.** Тиешле норматив хокукый актлар кабул ителгәнче, «Дәүләт хезмәте турында»гы Татарстан Республикасы Законының 13 статьясындагы 3,8,11 пунктларын, 15 статьясын гамәлгә кертүгә бәйле чыгымнар ясамаска, моңа элек кабул ителгән законнар нигезендә дәүләт хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү, матди һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү шартларына бәйле чыгымнар керми.

**55 статья.** Татарстан Республикасы республика бюджетының предприятиеләргә, учреждениеләргә һәм оешмаларга кире кайтарып бирмәү һәм кире кайтарып бирү шартларында бирелә торган акчаларын башка максатларда файдалану әлеге суммаларны кайтарып алу өчен һәм Россия Федерациясе Үзәк банкының гамәлдәге исәпкә алу ставкасының икеләтелгән күләмендә штраф салу өчен нигез булып тора.

Татарстан Республикасы республика бюджетыннан кире кайтару шарты белән бирелә торган акчаларны вакытында кире кайтармаган өчен дәүләт ярдәменең барлык рәвешләрен күрсәтү, шул исәптән салым түләмнәрен законнар нигезендә кичектереп тору кыскартыла яисә туктатыла.

Татарстан Республикасы республика бюджетының кире кайтару шарты белән бирелгән акчаларыннан файдаланганда төп бурыч акчаларын һәм шулай ук процентларны вакытыннан соңга калып түләгәндә һәр соңга калган көн өчен Россия Федерациясе Үзәк банкының гамәлдәге исәпкә алу ставкасының өч йөздән бер өлеше күләмендә пеня алына.

**56 статья.** Әлеге Законны 2000 елның 1 гыйнвареннан гамәлгә кертергә.

**Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев**

Казан шәһәре,
1999 елның 17 ноябре
№ 2438

*«2000 елга Татарстан Республикасы бюджет системасы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта*

## 2000 ЕЛГА АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫНА АКЧАЛАР БҮЛҮ

*мең сумнарда*

| Районнар исеме | Минераль ашламалар һәм үсемлекләрне яклау чаралары бәяләрен компенсацияләү | | | | Җирләрне тамырдан яхшырту | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Барысы | шул исәптән | | | Барысы | шул исәптән | | |
| | | минераль ашламалар сатып алуга | пестицидлар сатып алуга | органика чыгаруга | | известьлау | | культуртехник һәм эрозиягә каршы эшләр |
| | | | | | | Бюджет исәбеннән | җир салымы исәбеннән | |
| Әгерже | 6842 | 4014 | 2115 | 713 | 3165 | 440 | 2510 | 215 |
| Азнакай | 11607 | 6465 | 3407 | 1735 | 1845 | 100 | 570 | 1175 |
| Аксубай | 8113 | 4798 | 2528 | 787 | 5445 | 740 | 4180 | 525 |
| Актаныш | 8742 | 4993 | 2631 | 1118 | 9340 | 1250 | 7060 | 1030 |
| Алексеевск | 10343 | 6118 | 3224 | 1001 | 8230 | 1150 | 6530 | 550 |
| Әлки | 9198 | 5555 | 2927 | 716 | 8325 | 1150 | 6530 | 645 |
| Апас | 6862 | 3890 | 2050 | 922 | 4435 | 520 | 2930 | 985 |
| Әлмәт | 9405 | 5591 | 2946 | 868 | 2425 | 150 | 820 | 1455 |
| Арча | 12311 | 6835 | 3602 | 1874 | 9180 | 1220 | 6930 | 1030 |
| Әтнә | 4813 | 2614 | 1377 | 822 | 4880 | 680 | 3820 | 380 |
| Баулы | 5041 | 2959 | 1559 | 523 | 1775 | 160 | 910 | 705 |
| Балтач | 7629 | 4047 | 2133 | 1449 | 6890 | 920 | 5180 | 790 |
| Бөгелмә | 6715 | 3953 | 2083 | 679 | 1070 | 130 | 730 | 210 |
| Буа | 10552 | 5806 | 3059 | 1687 | 3955 | 520 | 2990 | 445 |
| Югары Ослан | 5201 | 3226 | 1700 | 275 | 3040 | 380 | 2160 | 500 |
| Биек Тау | 8322 | 4406 | 2322 | 1594 | 5160 | 670 | 3790 | 700 |
| Чүпрәле | 6862 | 3899 | 2054 | 909 | 8055 | 1100 | 6240 | 715 |
| Алабуга | 5924 | 3542 | 1866 | 516 | 4400 | 610 | 3500 | 290 |
| Зәй | 7994 | 4685 | 2469 | 840 | 4915 | 670 | 3780 | 465 |
| Зеленодол | 5021 | 2968 | 1564 | 489 | 3740 | 370 | 2120 | 1250 |
| Кайбыч | 5466 | 3187 | 1679 | 600 | 3315 | 480 | 2710 | 125 |
| Кама Тамагы | 5180 | 3081 | 1624 | 475 | 2310 | 240 | 1370 | 700 |
| Кукмара | 8191 | 4412 | 2325 | 1454 | 7270 | 930 | 5240 | 1100 |
| Лаеш | 6529 | 3804 | 2004 | 721 | 6090 | 810 | 4590 | 690 |
| Лениногорск | 6800 | 3960 | 2087 | 753 | 1085 | 100 | 540 | 445 |
| Мамадыш | 8918 | 4965 | 2617 | 1336 | 12705 | 1750 | 9520 | 1435 |
| Менделеев | 3277 | 1874 | 988 | 415 | 3385 | 480 | 2740 | 165 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Минзәлә | 8298 | 4763 | 2510 | 1025 | 7300 | 910 | 5140 | 1250 |
| Мөслим | 8199 | 4731 | 2493 | 975 | 4960 | 610 | 3490 | 860 |
| Түбән Кама | 6519 | 3726 | 1964 | 829 | 4640 | 590 | 3350 | 700 |
| Яңа Чишмә | 9185 | 5976 | 2622 | 587 | 2920 | 420 | 2380 | 120 |
| Нурлат | 8750 | 4928 | 2597 | 1225 | 3480 | 440 | 2460 | 580 |
| Питрәч | 7940 | 4537 | 2391 | 1012 | 5830 | 670 | 3830 | 1330 |
| Балык Бистәсе | 7896 | 4758 | 2507 | 631 | 7285 | 940 | 5720 | 625 |
| Саба | 5802 | 3345 | 1763 | 694 | 7345 | 1010 | 5750 | 585 |
| Сарман | 9289 | 5442 | 2868 | 979 | 2135 | 230 | 1320 | 585 |
| Спас | 8582 | 5205 | 2743 | 634 | 6205 | 850 | 4790 | 565 |
| Тәтеш | 7975 | 4649 | 2450 | 876 | 6605 | 850 | 4850 | 905 |
| Тукай | 8647 | 4894 | 2579 | 1174 | 8690 | 1020 | 5780 | 1890 |
| Теләче | 5152 | 2832 | 1492 | 828 | 5255 | 770 | 4330 | 155 |
| Чирмешән | 7087 | 4099 | 2160 | 828 | 3540 | 490 | 2750 | 300 |
| Чистай | 10583 | 6325 | 3333 | 925 | 6520 | 880 | 5020 | 620 |
| Ютазы | 3778 | 2143 | 1128 | 507 | 860 | 100 | 550 | 210 |
| Татарстан кошчылык сәнәгате | 4000 | | | 4000 | | | | |
| «Татплодоовощпром» | 16460 | 12000 | 1460 | 3000 | | | | |
| Химияләштерү станциясе | | | | | 10000 | 1500 | 8500 | |
| Татагрохимсервис | 4000 | | | 4000 | | | | |
| Үсемлек продукциясен сатып алу өчен дәүләт заказы булдыруның үзәкләштерелгән фонды | 230000 | 150000 | 80000 | | | | | |
| БАРЛЫГЫ: | 580000 | 350000 | 180000 | 50000 | 230000 | 30000 | 170000 | 30000 |

| | |
|---|---|
| Катнаш азык сатып алуга компенсация | 150000 |
| Нәсел эшенә, ясалма орлыкландыруга ярдәм итү | 53000 |
| Элиталы орлыкчылыкка ярдәм итү | 115000 |
| Техник яктан кабат коралландыру фонды | 620000 |
| Терлекчелек продукциясенә дотация | 200000 |
| Бюджет учреждениеләрен тоту һәм башка чыгымнар | 141214 |
| БАРЛЫГЫ: | 2089214 |

*«2000 елга Татарстан Республикасының бюджет системасы турында» Татарстан Республикасы Законына 2 кушымта*

# 2000 ЕЛГА РЕСПУБЛИКА ИНВЕСТИЦИЯ ПРОГРАММАСЫ

| Программаның инвестиция проектының, тармакларның исеме | Норматив документ исеме | Программаның, инвестиция проектының билгеләнеше | Финанслау (мең сумнарда) | | | | Нәтиҗәнең характеристикасы | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Финанслау чыганагы | 2000 ел бәләрендә программа буенча барысы | 2000 елның 1 гыйнварена көтелүче түләүләр | 2000 елга | Программа буенча | 2000 елның 1 гыйнварена көтеләчәк түләүләр | 2000 елга план |
| **1. Социаль үсеш** | | | | | | | | | |
| 1. «1999-2001 елларга «Татарстан балалары» дәүләт республика программасы | ТР Министрлар кабинеты карары, 22.12.98 № 1907 | Балалар өчен уңайлы шартлар тудыру, аларның социаль-икътисадый үсеш чорында социаль яклануын тәэмин итү | Республика бюджеты | 1480000 | 10000 | 10000 | | | |
| 2. «Татарстан Республикасы халыкларының телләре турында» Татарстан Республикасы Законы | «Татарстан Республикасы халыкларының телләре турында» Татарстан Республикасы Законы, 08.07.92 № 1560-XII | Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның телләрен үстерү | Республика бюджеты | | | 7200 | | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3. 1998-2000 елларга Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген үстерү программасы, шул исәптән: | ТР МК каршында юл хәрәкәте иминлеге комиссиясе карары, 1.03.97 | Юл хәрәкәте иминлеге дәрәҗәсен күтәрү | ТР ЭЭМ ЮХИДИ идарәсенең Юл хәрәкәте иминлеге фонды | 63000 | 38300 | 24032 | | | |
| 3.1. Юл хәрәкәте иминлеген үстерү чараларын иҗтимагый яклау оешмалары | | | | 51800 | 33700 | 18000 | Юл - транспорт һәлакәте аркасында балалар травматизмы арту (бер елга саны)<br>1999 ел 515 фараз 636 | | |
| 3.2. Юл-транспорт һәлакәте ихтимал булган участокларны ачыклау һәм бетерү | | | | 11200 | 4600 | 6032 | Юл - транспорт һәлакәте аркасында травматизм арту<br>1999 ел 3418 фараз 3798 | | |
| | | | Барлыгы: | 1543000 | 40100 | 41232 | | | |
| | | шул исәптән түбәндәге финанслау чыганаклары буенча: | | | | | | | |
| | | ТР ЭЭМ ЮХИДИ идарәсенең Юл хәрәкәте иминлеге фонды | | 63000 | 38300 | 24032 | | | |
| | | Республика бюджеты | | 1480000 | 1800 | 17200 | | | |
| | | | | | | | | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **2. Инфраструктура үсеше** | | | | | | | |
| **2.1. Җитештерүгә карамаган тармаклар инфраструктурасын үстерү** | | | | | | | |
| 1. 1995-2000 елларга ТР торак пунктларын, шәһәрләрне, эшче поселокларны газлаштыру | ТР Президенты Указы, 08.08.95 № 542 | ТР халкын челтәрле газ белән тулысынча тәэмин итү | Районнарны, шәһәрләрне, авылларны газлаштыру буенча бюджеттан тыш дәүләт фонды (республика бюджеты) | 2039100 | 1423100 | 515100 | Авылларны, шәһәрләрне һәм эшче поселокларны челтәрле газ белән тәэмин итү:<br>- газүткәргечләрнең озынлыгы (км)<br>14861,1 10682,6 14179,4 |
| | | | | | | | - газүткәргечләрнең озынлыгы (%)<br>100 76,3 95,4 |
| | | | | | | | - фатирларны газлаштыру (берәмлек)<br>262335 197312 248529 |
| | | | | | | | - фатирларны газлаштыру (%)<br>100 75,2 94,7* |
| | | | | | | | 1.01.95 елга торышы:<br>- газүткәргечләр озынлыгы - 10115,9 км<br>- газлаштырылган фатирлар саны - 792914 |
| 2. «Мәгариф» тармагы инфраструктурасы үсеше: мәктәпләрне төзү, реконструкцияләү | | Мәйданнар белән тәэмин итүне ихтыяҗи нормативлар дәрәҗәсенә һәм төзекләндерүнең нормативлар дәрәҗәсенә җиткереп тигезләү | ТР республика һәм җирле бюджетлары | | | 102300 | Тузган мәктәпләрнең санын киметү (берәмлек)<br>1.01.99 елга фактта<br>59 56 51<br>2000 елда 12 мәктәпне 2001-2002 елларда кертү өчен әзерләү<br>Татарстан Республикасында барлык мәктәпләр - 2454<br>Мәктәпләрдә ике сменада шөгыльләнүче укучыларның чагыштырма санын киметү (%) 1.01.99 елга фактта<br>23,1 21,5 20,5 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3. «Сәламәтлек саклау» тармагы инфраструктурасын үстерү: дәвалау-профилактикалау учреждениеләрен төзү, реконструкцияләү | | Халыкка медицина хезмәте күрсәтүнең дәрәҗәсен арттыру | ТР республика һәм җирле бюджетлары | | | 90300 | Медицина хезмәте күрсәтү дәрәҗәсен күтәрү<br>Халыкны дәвалау-профилакти-калау учреждениеләре белән тәэмин итү (10000 кешегә ятак- урын)<br>1.01.99 елга фактта<br>121,0<br>Россия Федерациясе дәүләт гарантияләре программалары буенча тәэмин ителеш нормасы 10000 кешегә 85,3 ятак-урын<br>Социаль чирләр (туберкулез, СПИД, онкология) буенча дәвалау-профилактикалау учреждениеләре челтәрен үстерү<br>1999 елда 120 ятак- урын<br>һәм<br>20 урын 3 объект |
| 4. «Мәдәният» тармагы инфраструктурасы үсеше: мәдәният учреждениеләрен төзү, реконструкцияләү | ТР МК карары, 21.03.96 № 216 | Мәдәният учреждениеләренен матди-техник базасын үстерү | Республика бюджеты | 710300 | 345600 | 39400 | Мәдәният объектларын гамәлгә кертү:<br>21 № 216 карар буенча<br>18, шул ис. №216 карар буенча<br>6, шул ис. № 216 карар буенча<br>5<br>1<br>«Мәдәният» тармагының барлык төр учреждениеләре саны - 4272 |
| 5. ТР ЭЭМның Янгынга каршы дәүләт хезмәте инфраструктурасы үсеше | | Техник коралланыш | ТР ЭЭМның Янгынга каршы дәүләт хезмәте идарәсенең «Янгын куркынычсызлыгы» агымдагы махсус счеты | | | 36300 | |
| 6. Торак-коммуналь хуҗалыгы инфраструктурасы үсеше | | | | | | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 6.1. Тузган торак фондын бетерү һәм ТР тузган торак кварталларын реконструкциялəү программасы | ТР Президенты Указы, 23.10.95 № VII-720 | ТР тузган торакны бетерү | ТР Бюджеттан тыш дәүләт торак фонды | | 2975200 (1998,1999 еллар) | 1759200 | Тузган торактан күченүче гаиләләр саны 46775 19423 6000 |
| 6.2. Бөек Ватан сугышында катнашучыларны торак белән тәэмин итү | ТР МК карары, 20.08.99 № 539 | Бөек Ватан сугышында катнашучыларның торак белән тәэмин ителешен нормативларга җиткерү | Республика бюджеты | | | 141500 | Торак шартларын яхшыртуга мохтажлардан - Бөек Ватан сугышында катнашучылар саны 1.01.99 елга 4050 3300 |
| 6.3. Торак шартларын яхшыртуга мохтаж халыкка адреслы социаль яклауны тәэмин итү | «Торак төзү яисә сатып алу өчен гражданнарга ташламалы кредитлар бирү турында нигезләмәне раслау хакында» ТР МК карары, 13.02.97 № 118 Яшь гаиләләргә торак сатып алуда дәүләт ярдәменең республика программасы (1997-2005 еллар) | Халыкның торак белән тәэмин ителешен нормативларга җиткерү | Республика бюджеты<br>ТР Юллар фонды<br>Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин итү фонды<br>ТР спирт, ликер-аракы һәм шәраб ясау сәнәгасен үстерү буенча бюджеттан тыш фонд | | 20000 | 20000<br>5400<br>6000<br>2000 | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 6.4. Торак-коммуналь хуҗалык инфраструктурасы үсеше | ТР МК карары, 17.02.97 № 127 | Су белән тәэмин итү, су бүлеп бирү инженер-техник инфраструктурасы үсеше | Республика бюджеты<br>ТР Экология фонды | | | 116500<br>21000 | |
| 7. Җитештерү тармагы булмаган башка объектларны төзү | | | Республика бюджеты<br>ТР Халыкны эш белән тәэмин итү фонды | | | 225000<br>9105 | |
| | | | Барысы: | 2749400 | 4763900 | 3089105 | |
| | | шул исәптән:<br>Республика бюджеты (районнарны, шәһәрләрне һәм авыл җирләрен газлаштыру буенча бюджеттан тыш дәүләт фонды аша) | | 2039100 | 1423100 | 515100 | |
| | | ТР республика һәм җирле бюджеты, шул исәптән: | | 710000 | 365600 | 735000 | |
| | | Казан шәһәре бюджеты | | | | 2155000 | |
| | | Республика бюджеты | | | | 520000 | |
| | | ТР Бюджеттан тыш дәүләт торак фонды | | | 2975200 (98-99 еллар) | 1759200 | |
| | | ТР ЭЭМ янгынга каршы көрәш хезмәте идарәсенең «Янгын куркынычсызлыгы» агымдагы махсус счеты | | | | 36300 | |
| | | ТР Юллар фонды | | | | 5400 | |
| | | ТР Халыкны эш белән тәэмин итү фонды | | | | 15105 | |
| | | ТР спирт, ликер-аракы һәм шәраб ясау сәнәгасен үстерү буенча бюджеттан тыш фонд | | | | 2000 | |
| | | ТР Экология фонды | | | | 21000 | |

| 2.2. Җитештерү тармаклары инфраструктурасы үсеше | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. Транспорт инфраструктурасы үсеше: | | | | | | | |
| 1.1. 1996-2000 елларга ТР автомобиль юлларын камилләштерү һәм үстерүнең комплекслы программасы | ТР МК карары, 29.07.96 № 618 | ТР авыл хуҗалыгы үзәк усадьбаларын һәм торак пунктларын асфальт-бетон юллар белән тәэмин итү | ТР Юллар фонды | 5403000 | 2966000 | 306000 | ТР авыл хуҗалыгы үзәк усадьбаларын һәм торак пунктларын асфальт-бетон юллар белән тәэмин итү (%):<br>100 54,9 56,2 |
| 1.2. Кама елгасы аша күпер төзү | ТР МК күрсәтмәсе, 23.11.93 № 1088-р «Кама елгасы аша күпер төзү проектын раслау турында» | ТР төньяк һәм көньяк территорияләрен автотранспорт элемтәсе белән тәэмин итү | ТР ЮФ | 4080000 | 700000 | 600000 | Өзерлек дәрәҗәсе (%):<br>100 17,2 31,9 |
| 1.3. Казан халыкара аэропортын реконструкцияләү | | Казан халыкара аэропортының статусын күтәрү | ТР ЮФ | 1380000 | 300000 | 256900 | Өзерлек дәрәҗәсе (%):<br>100 23,2 37,8 |
| 1.4. Сәнәга өчен лизинг фонды | ТР МК карарлары: 31.01.96 № 57 10.09.96 № 786 23.07.97 № 591 | «Татарстан» республика авиакомпаниясен финанс арендасы нигезендә самолетлар белән тәэмин итү | Республика бюджеты | - | - | 275000 | «Татарстан» республика авиакомпаниясен самолетлар белән тәэмин итү |
| 1.5. 1996-2023 елларда Казан метрополитенын төзү программасы | ТРМК карары 14.12.96 № 1056 | Казан шәһәрендә транспорт системасын камилләштерү | барысы:<br>РФ бюджеты<br>Казан шәһәре бюджеты | 8526000<br>4263000<br>4263000 | <br>52400<br>180400 | <br>30000<br>15000 | |
| | | | Барысы: | 19389000 | 4198800 | 1482900 | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | шул исәптән түбәндәге финанслау чыганаклары буенча: Республика бюджеты | | 4263000 | 180400 | 275000 | |
| | | ТР Юллар фонды | | 10863000 | 3966000 | 1162900 | |
| | | РФ бюджеты | | 4263000 | 52400 | 30000 | |
| | | Казан шәһәре бюджеты | | | | 15000 | |
| 3. Икътисадның реаль секторын үстерү | | | | | | | |
| 1. ТР минераль-чимал базасын, шул исәптән бүлекләр буенча, өйрәнү һәм җитештерү | | Перспектив мәйданнарны һәм ятмаларны эзләү һәм бәяләү, дефицит файдалы казылмаларны разведкалау, шулай ук торф, сапропель, җир асты төче һәм минераль суларын һәм башка файдалы казылмаларны разведкалау | ТР минераль ресурслар запасын җитештерү һәм файдалы казылмалар чыгаруның нәтиҗәлелеген арттыру фонды | | | 2175500 | |
| | | Ятмаларны фаразлауның, эзләүнең һәм разведкалауның яңа ысулларын эшләү һәм гамәлгә кертү<br>Җир асты байлыкларын, җир асты суларын һәм әйләнә-тирә табигать мохитен саклау | | | | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Каты файдалы казылмалар | «1993-2000 елларда ТР минераль-чимал базасын һәм жир асты байлыкларын өйрәнү һәм торгызу буенча дәүләт программасы (каты файдалы казылмалар жир асты сулары)», ТРМК карары, 15.02.93, № 18 | | | 1454000 | 854000 | 300000 | 1. Каты файдалы казылмалар запасының һәм аларны һәр ел чыгару күләмнәренең артуына чагыштырма (%):<br>1997 ел факт 10<br>1998 ел факт 9<br>1999 ел фараз 12<br>2000 ел план 20<br><br>2. Жир асты эчәр суларының һәм минераль суларның запаслары үсеше (%):<br>1997 ел факт 26,5<br>1998 ел факт 19,9<br>1999 ел фараз 30,0<br>2000 ел план 32,0 |
| Углеводород чималы | | | | | | 1875500 | Каты файдалы казылмалар запасының һәм аларны һәр ел чыгару күләмнәренең артуына чагыштырма (%)<br>1997 ел факт 25,0<br>1998 ел факт 45,7<br>1999 ел фараз 100,0<br>2000 ел план 100,0 |
| 2. Икътисадның реаль секторының инвестиция үсеше: | | Предприятиеләрнең икътисадый яктан үз-үзләрен тәэмин итү дәрәҗәсе | Барысы, шул исәптән Республика бюджетыннан кредит ТР хөкүмәте | 1352398<br><br>620000 | | 1587654<br><br>620000 | Зыянга эшләүче предприятиеләрнең санын киметү (%)<br>53,0 41,0 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | гарантияләре | 300000*) | | 300000*) | |
| | | | Салым ташламалары | 220000*) | | 220000*) | |
| | | | ТР Хосусыйлаштыру фонды | | | | |
| | | | Гомумтармак һәм тармакара фәнни тикшеренү һәм тәҗрибә-конструк-торлык эшләре фонды | 69298 | | 69298 | |
| | | | | 143100 | | 143100 | |
| | | | ТР спирт, ликер-аракы һәм шәраб әзерләү сәнәгасен үстерүнең бюджеттан тыш фонды | | | 235256 | |
| шул исәптән: «АлАЗ» | | | Республика бюджеты | 60000 | | 60000 | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Алабуга кирпеч заводы | | | ТР бюджеты | 5200 | | 5200 | |
| «Түбән Кама шин» ЗМШ ААҖ,«15,16,17,5 диаметрлы җиңел йөк машиналары шины җитештерү» | | | НИОКР фонды | 201690 | | 81570 | |
| «Ансат» күпмаксатлы җиңел вертолеты», КВЗ АҖ | | | Хөкүмәт гарантияләре | 157500 | | 157500 | |
| «Көнкүреш өчен суыткыч приборлар җитештерү», Зеленодол «ПОЗИС-ХОЛОД» суыткычлары заводы | | | Бюджет кредиты Салым ташламалары | 15000<br>14400 | | 15000<br>14400 | |
| «Зеленодол шәһәренең энергия сакланышы программасы», Зеленодол районы һәм Зеленодол шәһәре хакимияте | | | Бюджет кредиты НИОКР фонды | 8000<br>12000 | | 8000<br>12000 | |
| «Чаллы шәһәренең бюджет өлкәсе учреждениеләрендә энергияне исәпкә алу системасын кертү», Чаллы шәһәре хаки- | | | НИОКР фонды | 22750 | | 22750 | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| мияте | | | | | | | |
| 3. ТР кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм күрсәтү | • | Кече эшкуарлыкка ярдәм күрсәтү. Конкуренция мохитен үстерү | ТР кече һәм урта эшкуарлыгына ярдәм күрсәтү фонды (Республика бюджеты) | | 28670 | 25000 | Кече предприятиеләр санын арттыру (берәмлекләрдә) 217 48<br>Яңа эш урыннары булдыру (берәмлекләрдә) 868 500<br>Республика һәм жирле бюджетларны тулыландыру (мең сумнарда) 157700 29600 |
| 4. Фундаменталь тикшеренүләр һәм фәнни-техник прогресска ярдәм күрсәтү | | | Республика бюджеты | | | 27600 | |
| | | Барлыгы: | | 2806398 | 882670 | 3815754 | |
| | | шул исәптән:<br>ТР минераль ресурслары запасларын торгызу һәм файдалы казылмалар чыгаруның нәтиҗәлеген арттыру фонды | | 1454000 | 854000 | 2175500 | |
| | | ТР спирт, ликер-аракы һәм шәраб әзерләү сәнәгасен үстерүнең бюджеттан тыш фонды | | | | 235256 | |
| | | ТР Хөкүмәте гарантияләре | | 300000*) | | 300000*) | |
| | | Гомумтармак һәм тармакара фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләре фонды | | 143100 | | 143100 | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | ТР Хосусыйлаштыру фонды | | 69298 | | 69298 | |
| | | Салым ташламалары | | 220000*) | | 220000*) | |
| | | Республика бюджетыннан кредитлар | | 620000 | | 620000 | |
| | | Республика бюджеты, | | | 28670 | 52600 | |
| | | шул исәптән кире кайтару шарты нигезендә | | | | 25000 | |
| *) Республика бюджетыннан тыш сумма | | | | | | | |
| 4. Әйләнә-тирә мохитне саклау | | | | | | | |
| 1. Халыкның экологик иминлеген тәэмин итү буенча максатчыл комплексы программалар | | Халыкның экологик иминлеген тәэмин итү | | | 524600 (1997-1999 еллар) | 221140 | |
| 1.1. ТР атмосфера һавасын саклау (1997-2001 еллар) | ТРМК 17.02.97 ел № 127 карары | Атмосферага пычратучы матдәләр чыгару күләмнәрен киметү | ТР Экология фонды | | 52800 | 2000 | Атмосферага түбәндәге кушылмалар чыгаруны кыскарту (%):<br>күкерт<br>38 33 36<br>углеводородлар<br>35 31 33<br>үлчәнгән матдәләр<br>60 53 58 |
| 1.2. Су ресурсларын саклау һәм алардан нәтиҗәле файдалану (1997-2001 еллар) | Шул ук | Халыкны эчә торган су белән тәэмин итү | Шул ук | | 248200 | 80700 | Су объектларын пычрату дәрәҗәсен киметү (%)<br>60 53 58 |
| 1.3. ТР файдаланылган нефть продуктларын утильләштерү (1997-2001 еллар) | - « - | Әйләнә-тирә мохитне пычрату күләмнәрен киметү | - « - | | 8100 | 31200 | Нефть продуктлары калдыкларын яңадан эшкәртү күләмен арттыру (%):<br>25 22 25 |
| 1.4. ТР авыл хуҗалыгы комплексында та- | - « - | Җирләрне рекультивацияләү, зарарлы | - « - | | 126600 | 4300 | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| бигый байлыкларны саклау һәм торгызу | | матдәләр белән пычрату күләмен һәм аларның туплануын кимету | | | | | |
| 1.5. Татарстан Республикасының әйләнә-тирә табигать мохитен мониторинглау | - « - | Табигатьне саклау өлкәсендә карарлар кабул итүне мәгълумати тәэмин итү | - « - | | 25800 | 600 | |
| 1.6. ТР халкына экологик белем бирү | - « - | Халыкның экологик аңын булдыру | - « - | | 17200 | 3900 | |
| 1.7. Үсемлекләр һәм хайваннар дөньясын яңадан торгызу | - « - | Табигый байлыкларны экологик яктан яңадан торгызу | - « - | | 39600 | 7240 | |
| 1.8. Калдыкларны саклау, утильләштерү һәм яңадан эшкәртү (1999-2002 еллар) | ТР МК 4.10.99 ел № 651 карары | Әйләнә-тирә мохитнең пычрануы күләмен кимету | ТР Экология фонды | | 132900 | 68700 | Каты көнкүреш калдыклары полигоннарын гамәлгә кертү (берәмлекләрдә): 51 8 14<br>егәрлеге (мең м$^3$) 13720 3192 2726 |
| | | | ТР спирт, ликер-аракы һәм шәраб ясау сәнәгасен үстерү бюджеттан тыш фонды | | | 22500 | Гамәлдәге производстволарда чистарту корылмаларын төзүне тәгәлләү (%) 100 |
| 2. Урманнарны саклау<br>2.1. 1996-2000 | Татарстан Республ | Республиканың имән урманнарын | Республика һәм җирле бюджет, | | 40000 | | Урман белән капланган мәйданнарны саклау |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| елларга Татарстан Республикасы иманлекләрен торгызу программасы | икасы Министрлар кабинетының 21.05.96 ел № 419 карары | торгызу һәм саклау | шул исәптән: республика бюджеты<br>ТР Экология фонды | 89600 | 15000 | 4000<br>200 | 1,0 1,0 1,0<br>Саклау функцияләрен үтәүче урманнарның сакланышы, урманнарның барлык мәйданына %ларда<br>0,42 0,42 0,42 |
| 2.2. «1996-2000 елларга урманнарны янгыннардан саклауны һәм аларны корткычлардан һәм авырулардан яклауны яхшырту чаралары турында» программа | ТР МК 19.04.96 ел № 308 карары | Урманнарда янгынга каршы профилактика дәрәҗәсен күтәрү, корткычларны һәм авыруларны таратуны кисәтү һәм булдырмау | Республика һәм җирле бюджет, шул исәптән: республика бюджеты | 452300 | 78000<br>15000 | 6000 | - « - - « - - « - |
| | | Барлыгы: | | 541900 | 642600 | 231340 | |
| | | шул исәптән финанслау чыганаклары буенча:<br>Республика һәм җирле бюджет<br>шул исәптән Республика бюджеты<br>Татарстан Республикасының Экология фонды<br>Татарстан Республикасының спирт, ликер-аракы һәм шәраб ясау сәнәгасен үстерү бюджеттан тыш фонды | | 541900<br>89600 | 118000<br>30000<br>524600 | 10000<br>10000<br>198840<br>22500 | |

**Республика инвестиция программасы буенча финанслау, барлыгы**

| Финанслау чыганаклары | Финанслау (мең сумнарда) | | |
|---|---|---|---|
| | программа буенча барлыгы 2000 елгы бәяләрдә | 1.01.2000 елга кӛтелгән үтәлеш | 2000 елга |
| Программа буенча барлыгы: | 27439600 | 10511790 | 8630331 |
| Республика бюджеты | 8631180 | 2101290 | 1389900 |
| шул исәптән түбәндәгеләр аша: | | | |
| районнарга, шәһәрләргә һәм авыл торакларына газ кертү буенча дәүләт бюджеттан тыш фонды | 2039100 | 1423100 | 515100 |
| Республика бюджетыннан кредит | | | 620000 |
| Татарстан Республикасы Хөкүмәте гарантияләре | 300000 | | 300000 |
| Салым ташламалары | 220000 | | 220000 |
| Татарстан Республикасында Юллар фонды | 10863000 | 3966000 | 1168300 |
| Татарстан Республикасының Минераль ресурслар запасын торгызу һәм файдалы казылмалар чыгаруның нәтиҗәлелеген арттыру фонды | 1454000 | 854000 | 2175500 |
| Татарстан Республикасының Экология фонды | | 524600 | 219840 |
| Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин итү фонды | | | 15105 |
| ТР Эчке эшләр министрлыгының ЮХИДИ идарәсенең Юл хәрәкәте иминлеге фонды | 63000 | 38300 | 24032 |
| Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының Янгынга каршы дәүләт хезмәт идарәсенең «Янгын куркынычсызлыгы» агымдагы махсус счеты | | | 36300 |
| | | 2975200 (98,99 еллар) | 1759200 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Татарстан Республикасының Бюджеттан тыш дәүләт торак фонды | | | 259756 |
| Татарстан Республикасының спирт, ликер-аракы һәм шәраб ясау сәнәгасен үстерү бюджеттан тыш фонды | 171930 | | 143100 |
| Гомумтармак һәм тармакара фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләре фонды | 111700 | | 69298 |
| Татарстан Республикасының Хосусыйлаштыру фонды | 4263000 | 52400 | 30000 |
| Россия Федерациясе бюджеты | | | 230000 |
| Казан шәһәре бюджеты исәбеннән капитал салулар | | | |

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 770. Эшчәнлекнең аерым бер төрләре өчен йөкләнгән керемгә берләшкән салым турында

1 статья. **Гомуми нигезләмәләр**

1. Әлеге Закон, «Эшчәнлекнең аерым бер төрләре өчен алдан билгеләнгән керемгә бердәй салым турында» Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлекнең аерым бер төрләре өчен алдан билгеләнгән керемгә бердәй салым (алга таба - бердәй салым) билгеләүнең һәм гамәлгә кертүнең тәртибен билгели.

2. Әлеге Законның 3 статьясында билгеләнгән бердәй салым түләүчеләр тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә бердәй салымны түләү мәҗбүри.

3. Бердәй салым кертелгән көннән бу салымны түләүчеләрдән бюджеттан тыш дәүләт фондларына түләүләр, шулай ук, түбәндәгеләрдән гайре, "Россия Федерациясендә салым системасы нигезләре турында" Россия Федерациясе Законының 19-21 статьяларында каралган салымнар алынмый:

1. дәүләт пошлинасыннан;
2. таможня пошлиналарыннан һәм башка төрле таможня түләүләреннән;
3. лицензия һәм теркәү җыемнарыннан;
4. транспорт чараларын сатып алган өчен салымнан;
5. транспорт чаралары хуҗаларыннан алына торган салымнан;
6. җир өчен салымнан;
7. чит ил акчаларын һәм чит ил валютасында белдерелгән түләү документларын сатып алган өчен салымнан;
8. юридик зат барлыкка китермичә генә эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыручы физик затлардан, әлеге Законның 3 статьясында күрсәтелгән өлкәләрдә эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашырганда алына торган керемнәрдән гайре, теләсә нинди керемнәргә салымнан;
9. керемгә салымның тотып калынган суммаларыннан, шулай ук, салымнар турындагы Россия Федерациясе закон актларында түләүләрнең чыганагыннан салым тотып калу вазыйфасы билгеләнгән очракларда, өстәлгән бәяләргә салымнар һәм Россия Федерациясендә чыганактан керемнәргә салымнан.

2 статья. **Әлеге Законда кулланылучы төп төшенчәләр**

Әлеге Закон максатларында түбәндәге төп төшенчәләр кулла-

ныла:

алдан билгеләнгән керем - салым органнары һәм дәүләтнең башка органнары тикшерүләре барышында статистик тикшеренүләр юлы белән алынган мәгълүматлар, шулай ук бәйсез оешмалар бәяләүләре нигезендә, мондый керемне алуга турыдан-туры йогынты ясаучы факторларның бергәлеген исәпкә алып хисаплана торган, потенциаль кирәкле чыгымнарны чигергәннән соң бердәй салым түләүченең потенциаль мөмкин тулаем кереме ул;

база керемлелеге - төрле чагыштырырлык шартларда эшчәнлекнең аерым бер төрен билгеләүче физик күрсәткечнең теге яки бу берәмлегенә (мәйдан берәмлеге, сәүдә һәм утырту урыннары саны, эшләүчеләр саны, җитештерү куәте берәмлеге, һ.б.) карата кыйммәти чагылыштагы шартлы керемлелек ул;

база керемлелегенең арттыручан (киметүчән) коэффициентлары - бердәй салым түләү турында таныклык нигезендә гамәлгә ашырыла торган эшкуарлык эшчәнлеге (алга таба - таныклык нигезендәге эшчәнлек) нәтиҗәсенә теге яки бу факторның (эшчәнлек урыны, эшчәнлек төре) йогынты ясау дәрәҗәсен күрсәтүче коэф-фициентлар ул;

ваклап сату - сатучының үз товарын (җитештергән яисә сатып алган) яки комиссия шартнамәләре, йөкләмә яисә агент шартнамәсе нигезендә реализациягә кабул итеп алынган товарны реализацияләвенә карамастан, шәхси, гаиләдә, йорт-җирдә яисә башка төрле кулланылыш өчен товарларны үз сәүдә челтәре йә арендаланучы сәүдә нокталары (урыннары, биналары) аша ваклап сату эшчәнлеге ул;

ваклап сату челтәре - товарлар сату эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен каралган стационар һәм (яки) стационар булмаган сәүдә нокталары (урыннары) ул;

стационар сәүдә ноктасы (урыны) - сәүдә мәйданы (кибет, павильоны, стационар палатка, киоск, контейнер, склад, күргәзмә һәм (яки) офис бинасы (товарларны үрнәкләре буенча саткан очракта) һ.б.лар булган,шулай ук булмаган, сәүдә итү өчен даими махсуслаштырылган (шул исәптән күп функцияле сәүдә комплекслары яисә үзәкләре структурасына керүче) урын ул;

стационар булмаган сәүдә ноктасы (урыны) - сәүдә мәйданы булмаган, китереп сату чаралары (автолавкалар, фургоннар, арбалар, сату автоматы, сүтеп җыелмалы палатка) ярдәмендә сату өчен һәм таратып йөреп шул исәптән сатып алучының өендә сәүдә итү (лотоклар, кәрзиннәр) өчен бирелгән урын ул;

сәүдә мәйданы - функциональ (территориаль) аерымланган

сәүдә бинасының йә сәүдә залының, шулай ук күп функцияле сәүдә комплексына (үзәгенә) керүче йә үрнәкләре буенча товарлар сату өчен билгеләнгән һәм аңа (бинага, залга, урынга) сатучылар тарафыннан сатып алучыларны кертү каралган махсуслаштырылган сәүдә (күргәзмә) урынының мәйданы ул;

җәмәгать туклануы - ашханәләрдә, рестораннарда, кафеларда, барларда, җәмәгать туклануының стационар булмаган һәм башка нокталарында җитештерелгән үз кулинар продукцияләрен (ашамлыкларны, кулинар әйберләрне, ярымфабрикатларны), кулинар эшкәртү узмаган сатып алынган товарларны, шулай ук сатып алучыларга, шул исәптән өйләренә һәм халык заказы буенча җибәрелгән башка төрле сатып алынган товарларны халыкка сату эшчәнлеге ул;

эшләүче белгеч - хезмәт вазыйфалары эшчәнлекнең билгеле бер төрен яки аның теләсә кайсы бер өлешен гамәлгә ашыру белән турыдан-туры бәйләнгән, үз функцияләрен хезмәт шартнамәсе яки граждан - хокукый характердагы шартнамә нигезендә башкаручы физик зат, шулай ук эшчәнлекнең билгеле бер төрен гамәлгә ашыру белән турыдан-туры бәйләнгән функцияләрне мөстәкыйль башкаручы индивидуаль эшкуар ул. Вазыйфлары төп эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру белән турыдан-туры бәйләнмәгән хезмәт күрсәтүче персонал эшләүче белгечләр рәтенә кертелми;

ягулык-майлау материаллары - автомобильләргә ягулык салу (традицион, модульле, контейнерлы) станцияләре аша һәм стационар булмаган рәвештә чыгып сәүдә иткәндә реализацияләнә торган автомобиль бензины, дизель ягулыгы, карбюраторлы двигательләр өчен майлар, дизельле двигательләр өчен майлар, карбюраторлы һәм дизельле двигательләр өчен майлар һәм газ ул.

3 статья. **Салым түләүчеләр**

Бердәй салым түләүчеләр (алга таба - салым түләүчеләр) - билгеләнгән тәртиптә теркәлгән һәм эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыручы юридик затлар (алга таба — оешмалар) һәм юридик зат барлыкка китермичә генә эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыручы физик затлар (алга таба - индивидуаль эшкуарлар) ул:

а) оешмалар:

физик затларга көнкүреш хезмәтләре күрсәтү (аяк киемнәрен, күн әйберләрен, мех әйберләрне ремонтлау, өс киемнәре тегү һәм ремонтлау; сәгатьләрне һәм ювелир әйберләрен ремонтлау; көнкүреш техникасын һәм шәхси куллану әйберләрен ремонтлау; металл әйберләр ремонтлау һәм әзерләү; машиналар, җиһазлар һәм приборлар, оештыру техникасын һәм периферия җиһазларын ре-

монтлау; автотранспорт чараларына сервис хезмәте һәм халыкка башка көнкүреш хезмәтләре күрсәтү, шул исәптән фото һәм кино хезмәтләрен күрсәтү; кинофильмнардан гайре, прокат;

физик затларга чәчтараш хезмәтләре күрсәтү (чәчтарашханәләр эшчәнлеге);

физик затларга медицина хезмәтләре күрсәтү;

физик затларга косметология хезмәтләре күрсәтү (шул исәптән косметик салоннарда);

физик затларга ветеринария һәм зоология хезмәтләре күрсәтү;

җәмәгать туклануы (рестораннар, кафелар, барлар, ашханәләр, стационар булмаган җәмәгать туклануының 50 гә кадәр эшләүчесе булган нокталары һәм башка нокталары эшчәнлеге), моңа ябык челтәрдәге җәмәгать тукլануы керми.

Әлеге Закон максатларында ябык челтәрдәге җәмәгать тукланүы дип оешмалар хезмәткәрләренә оешмалар ашханәләрендә әзерләнгән үз кулинар продукциясен, кулинар эшкәртүсез сатыла торган товарларны шулай ук оешма хезмәткәрләренә, шул исәптән аларның өйләренә җибәрелгән кулинар продукцияне һәм сатыла торган товарларны сату эшчәнлеге танылa;

- 30 га кадәр эшләүчесе булган кибетләр, палаткалар, базарлар, лотоклар, лареклар, сәүдә павильоннары һәм сәүдә оештыруның башка урыннары, шул исәптән стационар сәүдә мәйданы булмаган урыннар аша гамәлгә ашырыла торган ваклап сату;

- 100 гә кадәр эшләүчесе булган оешмалар тарафыннан автотранспорт хезмәте күрсәтү, моңа маршрутлы таксиларда коммерция нигезендә пассажирлар йөртү хезмәтләре керми;

- маршрутлы таксиларда коммерция нигезендә пассажирлар йөртү хезмәтләре күрсәтү;

- автомобильләрне вакытлыча куеп тору урыннары һәм гаражлар биреп тору хезмәтләре күрсәтү;

- ягулык-майлау материалларын ваклап сату;

б) индивидуаль эшкуарлар:

- физик затларга көнкүреш хезмәтләре күрсәтү (аяк киемнәре, күн, мех әйберләрен ремонтлау, өс киемнәре тегү һәм ремонтлау, сәгатьләрне һәм ювелир әйберләрне ремонтлау, көнкүреш техникасын һәм шәхси куллану әйберләрен ремонтлау, металл әйберләрне ремонтлау һәм әзерләү, машиналар, җиһазлар һәм приборлар, оештыру техникасын һәм периферия җиһазларын ремонтлау, автотранспорт чараларына сервис хезмәте һәм халыкка башка көнкүреш хезмәте күрсәтү, шул исәптән фото һәм кино хезмәте күрсәтү, ки-

нофильмнар прокатлаудан гайре, прокат;

- физик затларга чәчтараш хезмәтләре күрсәтү (чәчтарашханәләр эшчәнлеге);

- физик затларга медицина хезмәтләре күрсәтү;

- физик затларга косметология хезмәтләре күрсәтү (шул исәптән косметик салоннарда);

- физик затларга ветеринария һәм зоология хезмәтләре күрсәтү;

- җәмәгать туклануы (рестораннар, кафелар, барлар, ашханәләр, стационар булмаган җәмәгать туклануының 50 гә кадәр эшләүчесе булган нокталары һәм башка нокталары эшчәнлеге);

- 30 га кадәр эшләүчесе булган кибетләр, палаткалар, базарлар, лотоклар, лареклар, сәүдә павильоннары һәм башка сәүдә оештыру урыннары, шул исәптән, стационар сәүдә мәйданы булмаган сәүдә урыннары аша гамәлгә ашырыла торган ваклап сату;

- ягулык-майлау материалларын ваклап сату;

- ремонт-төзелеш хезмәтләре күрсәтү (төзелеп беткән биналарны һәм корылмаларны яки аларның кайбер өлешләрен төзү, биналарны җиһазлау, төзелеш участогын әзерләү, биналар һәм корылмалар яки аларның кайбер өлешләрен ремонтлау һәм төзү буенча бүтән хезмәтләр күрсәтү, территорияләрне төзекләндерү);

- кыска вакытка килеп яшәүчеләргә хезмәтләр күрсәтү;

- консультацияләр бирү, шулай ук бухгалтерлык, аудиторлык һәм юридик хезмәтләр күрсәтү, белем бирү, репетиторлык, мөгаллимлелек һәм мәгариф өлкәсендәге бүтән эшчәнлек;

- автотранспорт хезмәтләре күрсәтү, моңа маршрутлы таксиларда коммерция нигезендә пассажирлар йөртү хезмәтләр күрсәтү керми;

- маршрутлы таксиларда коммерция нигезендә пассажирлар йөртү хезмәтләре күрсәтү;

- автомобильләрне вакытлыча куеп тору урыннары һәм гаражлар биреп тору буенча хезмәтләр күрсәтү.

Филиаллары, вәкиллекләре һәм эшчәнлекне гамәлгә ашыруның башка урыннары булган, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан оешмалар бердәй салымны филиаллары, вәкиллекләре, эшчәнлекне гамәлгә ашыруның башка урыннары урнашкан җирдә түлиләр.

Филиаллары,вәкиллекләре һәм эшчәнлекне гамәлгә ашыруның башка урыннары булган оешмалар урнашкан җир буенча да, шулай ук үз филиалының, вәкиллегенең, эшчәнлекне гамәлгә ашы-

руның башка урыны буенча да салым органында салым түләүче буларак исәпкә куелырга тиеш.

Әлеге Закон максатларында, «эшчәнлекне гамәлгә ашыруның башка урыны" дип оешманың мөстәкыйль балансы һәм исәп-хисап счеты булган, шулай ук мөстәкыйль балансы һәм аерым исәп-хисап счеты булмаган һәм аны төзегән юридик затның гамәлгә кую документларында күрсәтелгән (күрсәтелмәгән), шулай ук баш предприятие теркәлгән урыннан читтә күчемсез мөлкәте һәм транспорт чаралары булган бүлекчәсе таныла.

Индивидуаль эшкуарлар бердәй салымны яшәү урынында яисә эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру урынында түлиләр.

Индивидуаль эшкуарлар эшчәнлекне гамәлгә ашыруның һәр урынындагы салым органнарында салым түләүче буларак исәпкә куелырга тиеш.

Оешмалар һәм индивидуаль эшкуарлар эшчәнлекне Россия Федерациясенең бердәй салым алынмый торган башка субъекты территориясендә гамәлгә ашырган очракта, индивидуаль эшкуарлар салым түләүне - яшәү урынында, ә оешмалар салым исәбенә куелган урында башкаралар. Әгәр Россия Федерациясенең бүтән субъекты территориясендә бу территориядә түләү мәҗбүри булган бердәй салым кертелгән булса, салымны ике мәртәбә түләтмәс өчен Татарстан Республикасы территориясендә бердәй салым алынмый. Түләнгән сумма эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру урынындагы салым органы биргән белешмә белән расланa.

Россия Федерациясенең башка субъекты территориясендә билгеләнгән тәртиптә теркәлгән, әмма эшкуарлык эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыручы оешмалар һәм индивидуаль эшкуарлар Татарстан Республикасында эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру урынында салым исәбенә куелырга тиеш.

Әлеге Законны куллану максатларында, оешмаларда (филиалларда, вәкиллекләрдә һәм эшчәнлекнең башка урыннарында) җәмәгать тукланувы, ваклап сату һәм транспорт хезмәтләре күрсәтү өлкәсендә эшләүчеләрнең санын билгеләгәндә, эшләүчеләрнең уртача саны һәр сәүдә ноктасы (филиалы, вәкиллеге, эшчәнлекнең башка урыны) буенча аерым исәпкә алына, моңа бер үк вакытта берничә урында эшләүчеләр (шул исәптән әлеге кибетнең үзендә бер үк вакытта берничә урында эшләүчеләр), граждани-хокукый характердагы шартнамәләр буенча эшләүчеләр, шулай ук оешманың идарә органнарында эшләүчеләр дә керми.

Эшләүчеләрнең уртача санын билгеләү гамәлдәге законнар

нигезендә башкарыла.

Инвалидларның иҗтимагый оешмаларына, устав капиталы тулысынча инвалидларның иҗтимагый оешмалары кертемнәреннән торган оешмаларына, шулай ук мөлкәтенең бердәнбер милекчесе инвалидларның иҗтимагый оешмалары булган предприятиеләргә һәм учреждениеләргә ихтыярый рәвештә бердәй салым түләүгә күчү яки салымнарның гамәлдәге тәртибен саклап калу хокукы бирелә.

4. Оешмалар һәм индивидуаль эшкуарлар җирле үзидарә органнары карарлары буенча үткәрелә торган кыска вакытлы ярминкәләрдә һәм бүтән гамәлләрдә стационар булмаган рәвештә чыгып сәүдә итүдән бердәй салым түләүчеләр булып исәпләнмиләр.

4 статья. **Алдан билгеләнгән керемгә бердәй салым салу объекты**

Чираттагы календарь аена алдан билгеләнгән керем бердәй салымны кулланганда салым салу объекты була. Бердәй салым буенча салым чоры итеп бер квартал билгеләнә.

Алдан билгеләнгән керем мөстәкыйль рәвештә түләүче тарафыннан түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

M= C*N*D*E*F*G*J*K*L*

M — йөкләнгән керем;

C — физик күрсәткеч берәмлегенә карата әлеге Законның 1-9 нчы кушымталарында китерелгән база керемлелеге;

N — физик күрсәткечнең берәмлек саны (сәүдә мәйданы - кв.метрларда, сәүдә урыннары саны, җәмәгать туклануы предприятиеләренең хуҗалык эшчәнлегендә файдаланыла торган урыннар саны, эшләүче белгечләр саны, эш урыннары саны, транспорт чаралары берәмлекләре саны һ.б.);

D — эшчәнлекнең ярдәмче төрләрен исәпкә алучы арттыручан (киметүчән) коэффициент;

E —эшкуарлык эшчәнлеген алып бару үзенчәлекләрен торак пунктның тибына бәйле рәвештә исәпкә алучы арттыручан (киметүчән) коэффициент;

F — эшнең тәүлеклелек коэффициенты;

G — өстәмә инфраструктураны файдалану мөмкинлеге коэффициенты;

J — күрсәтелүче хезмәтләрнең сыйфатын исәпкә алучы коэффициент;

K — автотранспорт чаралары паркының корректировкалаучы коэффициенты;

L — реализацияләнүче ягулык-майлау материаллары ассор-

тиментын исәпкә алучы коэффициент.

Эшчәнлекнең аерым төрләре өчен корректировкалаучы коэффициентлар күләме әлеге Законның 1-9 нчы кушымталарында китерелгән.

3. «Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиациягә дучар булган гражданнарны социаль яклау турында» (аннан соңгы үзгәрешләре һәм өстәмәләре белән) 1991 елның 15 маендагы РСФСР Законы нигезендә Чернобыль һәлакәте аркасында радиация йогынтысына дучар булган гражданнар-индивидуаль эшкуарларга, башка дәүләтләр территориясендәге хәрби хәрәкәтләрнең ветераннарына, Бөек Ватан сугышында катнашучыларга, I һәм II группа инвалидларга, балачактан инвалидларга, шулай ук өч һәм аннан да күбрәк балалы ата-аналарга физик күрсәткеч берәмлегенең база кеременә карата бердәй салымны исәпләгәндә 0,7 коэффициенты кулланыла.

5 статья. **Бердәй салым ставкасы**

Бердәй салым ставкасы алдан билгеләнгән керемнең 20 проценты күләмендә билгеләнә.

6 статья. **Салым түләүчеләр тарафыннан бухгалтерлык исәбен алып бару тәртибе**

Бердәй салым түләүчеләр үз керемнәре һәм чыгымнарының исәбен алып барырга, шулай ук исәп-хисап һәм касса операцияләрен алып бару тәртибен үтәргә тиеш.

Бердәй салым түләүгә күчү салым түләүчеләрне салым органнарына һәм дәүләтнең бухгалтерлык, салым һәм статистика буенча бүтән органнарына хисап бирүнең Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән бурычлардан азат итми.

Таныклык нигезендә эшчәнлекнең берничә төрен гамәлгә ашырганда, керемнәр һәм чыгымнар исәбе һәр эшчәнлек төре буенча аерым алып барыла.

Таныклык нигезендә эшчәнлек алып бару белән беррәттән бүтән эшкуарлык эшчәнлеген (алга таба – бүтән эшчәнлек) гамәлгә ашыручы салым түләүчеләр таныклык нигезендәге эшчәнлек барышында һәм бүтән эшчәнлек барышында үзләре башкара торган хуҗалык операцияләренең, йөкләмәләренең, мөлкәтнең аерым бухгалтерлык исәбен алып баралар.

7 статья. **Бердәй салым түләүгә күчү, исәп-хисап ясау, бердәй салымны исәпләп чыгару һәм түләү тәртибе. Бердәй салым түләү турында таныклык**

Индивидуаль эшкуарлар әлеге Закон рәсми рәвештә басылып чыккан көннән алып бер айдан да соңга калмыйча, ә оешмалар әлеге Законның 10 статьясындагы 3 пунктында билгеләнгән вакытта

салым исәбенә алыну урынындагы салым органына чираттагы салым чорында түләнергә тиешле бердәй салым суммасы исәп-хисабын тапшырырга тиеш, ул әлеге Законның 4 статьясында билгеләнгән формула буенча аларның үзләре тарафыннан мөстәкыйль исәпләп чыгарыла.

Алга таба бердәй салым исәп-хисабы салым түләүче тарафыннан квартал саен, салым чорына кадәрге айның 1 еннән соңга калмыйча, исәп-хисапның расланган формасы (10 нчы кушымта) нигезендә кертелә.

Исәп-хисаптагы физик күрсәткеч берәмлегенең база керемлелеге шушы кварталда эшкуарлык эшчәнлеге гамәлгә ашырыла торган айлар саныннан чыгып билгеләнә.

Әгәр салым түләүче агымдагы айның 15 енә кадәр эшкуарлык эшчәнлегенә керешкән булса, квартал исәп-хисабы бөтен бер айлык эшне 15 еннән соң ярты айлык эшне исәпкә алып кертелә.

Индивидуаль эшкуар яисә оешма таныклык нигезендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру буенча берничә урынга ия булганда, бердәй салым суммасы исәп-хисабы мондый урыннарның һәркайсы буенча аерым-аерым тапшырыла. Салым органнары тапшырылган исәп-хисапларда китерелгән белешмәләрне тикшерә һәм ун көн эчендә исәп-хисапларның күчермәләрен оешма яисә индивидуаль эшкуар исәптә торучы салым органы адресына җибәрә.

2. Салым түләүче оешманы, индивидуаль эшкуарны салым исәбенә кую урынындагы салым органы, исәп-хисапны алганнан соң салым чоры башланырга өч көннән дә соңга калмыйча, салым түләүчегә аны бердәй салым түләүгә күчерү турында рәсми хәбәр итә.

Язма хәбәрдә эшкуарлык эшчәнлеге гамәлгә ашырыла торган һәр урын (кибет, ларек, палатка, кафе, сәүдә урыны һ.б.) буенча чираттагы салым чорына салым түләүчегә билгеләнгән бердәй салымның тәгаен суммалары күрсәтелә.

3. Исәп-хисапларны тикшерү һәм салым түләүчене бердәй салым түләүгә күчерү турындагы язма хәбәр җибәрү бердәй салым суммасының күрсәтелгән исәп-хисапларын алган көннән бер айдан да озакка сузмыйча башкарыла.

4. Салым түләүче үзенең бердәй салым түләүгә күчерелүе турында язма хәбәр алганнан соң, бердәй салымны салым чорының агымдагы аеның 1 еннән дә соңга калмыйча, суммасын аванс рәвешендә түләү юлы белән календарь ае өчен бердәй салым суммасының 100 проценты күләмендә ай саен түләргә тиеш.

Бердәй салымны керткәннән соң кабат теркәлгән оешмалар, оешманы теркәгән көннән соң алты айдан да соңга калмыйча, әлеге салымны түли башлыйлар. Оешма гаризасы буенча әлеге чор кыскартылырга мөмкин.

5. Салым түләүче бердәй салым түләүне 3, 6, 9 яки 12 ай өчен бердәй салым суммаларын аванс рәвешендә күчерү юлы белән кертә ала. Бу очракта салым түләүче түләргә тиешле бердәй салым суммасы 2, 5, 8 һәм 11 процентларга кими.

6. Салым түләүчене бердәй салым түләүгә күчерү турындагы язма хәбәр, түләү йөкләмәсенең күчермәсе (түләү турындагы квитанция) салым түләүченең бердәй салым түләү турындагы таныклык рәвешендәге бердәй салым түләгәнлеген раслаучы документ бирү өчен нигез булып тора.

7. Һәр эшчәнлек төренә аерым таныклык бирелә. Таныклык нигезендә эшчәнлекне гамәлгә ашыруга ике һәм аннан да артык аерым урнашкан урынга (палаткалар, лареклар, кафе, кибетләр һ.б.) ия булган салым түләүчеләргә таныклык мондый урыннарның һәркайсына бирелә.

8. Таныклык биргәндә шулай ук эшкуарлык эшчәнлеге гамәлгә ашырылу урынындагы салым органында саклана торган икенче нөсхә дә тутырыла. Эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашырганда таныклыкның теләсә кайсы күчермәсен (шул исәптән нотариаль расланганнарын да) файдалану рөхсәт ителми.

9. Таныклык салым түләүче бердәй салым түләгән чор өчен бердәй салым түләгән көннән өч көннән дә соңга калмыйча салым түләүчегә тапшырыла.

10. Норматив хокукый актларда билгеләнгән каттый хисаплылык документлары белән эш итү кагыйдәләре бу таныклыкка да кагыла.

Таныклыкны югалткан очракта, ул кабат бирелми. Бу очракта салым түләүчегә калган салым чорына «Югалган таныклык урынына» дигән тамга салып яңа таныклык бирелә. Калган салым чорына яңа таныклык өчен түләү таныклык хакының 20 процентын тәшкил итә.

Калган салым чорына таныклыкны кабат югалткан очракта, калган салым чоры өчен таныклык 100 процент бәясенә сатып алына.

11. Таныклык беренче тапкыр бирелгәндә аерым түләү алу рөхсәт ителми.

12. Салым түләүче таныклык нигезендә эшкуарлык эшчәнлеген агымдагы айның 15 енә кадәр туктатканда, салым сум-

масы - агымдагы айның яртысы өчен, 15 еннән соң туктатканда, агымдагы бөтен бер ай өчен исәпләп чыгарыла. Салым салу объекты урнашкан урындагы салым органына тиешле гариза биргән көннән 10 көн вакыт үткәч, эшкуарлык эшчәнлеге туктатылган булып санала.

Салым түләүче таныклык нигезендә эшкуарлык эшчәнлеген туктатканда һәм ул бер хисап чорыннан (кварталыннан) артыграк аванс түләүләре керткән булса, аванс рәвешендә түләнгән бердәй салым суммасы тулы салым чоры (квартал) өчен кайтарып бирелергә йә башка эшчәнлек төрләре буенча салымнар түләү булып хисапланырга тиеш.

8 статья. **Бердәй салым суммаларын күчерү тәртибе**

1. «Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында үзара эшләр бүлешү һәм вәкаләтләр алмашу турында» Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Шартнамәсе нигезендә Россия Федерациясе белән Татарстан Республикасы хөкүмәтләренең үзара бюджет мөнәсәбәтләре турындагы килешүләрен исәпкә алып, оешмалар түли торган бердәй салым суммалары федераль бюджетка, бюджеттан тыш дәүләт фондларына, шулай ук Татарстан Республикасының республика бюджетына һәм җирле бюджетларга түбәндәге күләмнәрдә күчерелә:

а) федераль бюджетка - бердәй салымның гомуми суммасынан 21 процент;

б) Россия Федерациясенең бюджеттан тыш дәүләт фондларына - бердәй салымның гомуми суммасыннан 21, 775 процент, шуның:

Россия Федерациясе Пенсия фондына - 18,35 процент;

Россия Федерациясе Социаль иминият фондына - 3,425 процент.

Оешмалар, индивидуаль эшкуарлар «Дәүләт пенсия иминияте системасында индивидуаль (персональләштерелгән) исәп турында»гы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Пенсия фондына мәгълүматлар кертәләр;

в) Татарстан Республикасының республика бюджетында берләштерелгән максатчыл бюджет фондларына - 11,225 процент; шуның:

Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте фондына - 2,925 процент;

Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин итү

дәүләт фондына - 1 процент;

Татарстан Республикасында Юллар фондына - 7,0 процент;

«Янгын куркынычсызлыгы» махсус счетына - 0,3 процент;

г) Татарстан Республикасының Бюджеттан тыш дәүләт торак фондына - 1,0 процент;

д) 2000 елда Татарстан Республикасының республика бюджеты белән җирле бюджетлары арасында 50 шәр процент итеп бүлеп, Татарстан Республикасының республика бюджетына һәм җирле бюджетларына - 45 процент.

Индивидуаль эшкуарлар түли торган бердәй салым суммалары түбәндәге күләмнәрдә түбәндәгеләргә күчерелә:

а) җирле бюджетларга - бердәй салымның гомуми суммасыннан 75 процент;

б) бюджеттан тыш дәүләт фондларына - бердәй салымның гомуми суммасыннан 25 процент, шуның :

Россия Федерациясе Пенсия фондына - 22,725 процент;

Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте фондына - 2,275 процент.

Салым түләүчеләр үзләренә хезмәт күрсәтүче банкка бердәй салым күчерү өчен бер түләү йөкләмәсе тапшыралар.

4. Киләсе елларда бердәй салымны Татарстан Республикасының республика бюджеты белән җирле бюджетлар арасында бүлү чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджет системасы турында Татарстан Республикасы законында билгеләнә торган нормативлар буенча башкарыла.

9 статья. **Әлеге Законны бозган өчен җаваплылык**

Әлеге Законны бозган өчен җаваплылык законнар нигезендә билгеләнә.

10 статья. **Йомгаклау нигезләмәләре**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән гамәлгә керелә.

Әлеге Закон бердәй салым буенча чираттагы салым чоры башланырга бер айдан да соңга калмыйча рәсми басылып чыгарга тиеш.

Бердәй салым түләүче оешмалар бердәй салымны түләүгә 2001 елның 1 гыйнвареннан күчәләр һәм салым исәбенә кую урындагы салым органына әлеге Законның 4 статьясында билгеләнгән формула буенча үзләре мөстәкыйль исәпләгән бердәй салымның чираттагы салым чорында түләнергә тиешле исәп-хисабын 2000 елның 1 декабреннән дә соңга калмыйча бирәләр.

4. Әлеге Закон гамәлгә кергән көннән«Россия Федерация-

сендә кече эшкуарлыкка дәүләт ярдәме турында» 1995 елның 14 июнендәге 88-ФЗ номерлы Федераль закон, «Кече эшкуарлык субъектлары өчен салым салу, аларны исәпкә алу һәм хисаплылыкның гадиләштерелгән системасы турында» 1995 елның 29 декабрендәге 222-ФЗ номерлы Федераль закон салым салучыларга карата «Эшчәнлекнең аерым бер төрләре өчен алдан билгеләнгән керемгә бердәй салым турында»гы Федераль законның 11 статьясында билгеләнгән тәртиптә кулланыла.

5. Әлеге Закон гамәлгә кергән көннән ике ай вакыт эчендә түбәндәгеләрне үтәүне Татарстан Республикасы Президентына тәкъдим итәргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар кабинетына йөкләргә:

Татарстан Республикасының салым салу турындагы норматив хокукый актларын әлеге Законга яраклаштыру хакында тәкъдимнәр әзерләргә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертергә;

үз норматив хокукый актларын әлеге Законга яраклаштырырга.

**Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев**

Казан шәһәре,
1999 елның 17 ноябре
№ 2439

*1 нче кушымта*

Физик күрсәткечләр, база керемлелеге һәм арттыручан (киметүчән) коэффициентлар

| Эшчәнлек өлкәләре | Эшчәнлекнең шушы төрен характерлаучы физик күрсәткечләр (N) | Физик күрсәткеч берәмлегенең база керемлелеге, елына бер берәмлеккә сумнарда (С) | Эшчән-лекнең икенчел төрләренә арттыручан (киме-түчән) коэф. (Д) | Торак пункты тибына арттыручан (кимстүчән) коэффициент (Е) | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Казан | республика буйс. шәһәрләр | район буйс. шәһәрләр | башка торак пункт-лары |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| Индивидуаль эшкуарларның ремонт-төзелеш хезмәтләрен күрсәтүе | Эшләүче белгечләр саны | 24300 | 0,8-1,2 | 1,0 | 0,8 | 0,7 | 0,4 |
| - төзелеп бетмәгән биналарны, корылмаларны яисә аларның өлешләрен төзү | | - " - | 1,0 | - " - | - " - | - " - | - " - |
| - биналарны җиһазлау, төзелеш участогын әзерләү һәм биналарны, корылмаларны яисә аларның өлешләрен ремонтлау буенча башка хезмәт күрсәтүләр | | | 1,2 | - " - | - " - | - " - | - " - |
| - территорияләрне төзекләндерү | | - " - | 0,8 | - " - | - " - | - " - | - " - |
| | | | | | | | |

| Эшчәнлек өлкәләре | Эшчәнлекнең шушы төрен характерлаучы физик күрсәткечләр (N) | Физик күрсәткеч берәмлегенең база керемлелеге, елына бер берәмлеккә сумнарда (С) | Эшчәнлекнең икенчел төрләренә арттыручан (киметүчән) коэф. (Д) | Торак пункты тибына арттыручан (киметүчән) коэффициент (Е) | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Казан | республика буйс. шәһәрләр | район буйс. шәһәрләр | башка торак пунктлары |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| Физик затларга түбәндәге хезмәтләрне күрсәтү: | Эшләүче белгечләр саны | 18790 | 0,5-2,0 | 1 | 0,8 | 0,7 | 0,4 |
| - аяк киемнәрен ремонтлау | | - " - | 1,0 | - " - | - " - | - " - | - " - |
| - күн һәм мех әйберләрен ремонтлау | | - " - | 1,5 | - " - | - " - | - " - | - " - |
| - кием-салым тегү һәм ремонтлау | | - " - | 1,0 | - " - | - " - | - " - | - " - |
| - сәгатьләр һәм ювелир әйберләр ремонтлау | | - " - | 1,0 | - " - | - " - | - " - | - " - |
| - көнкүреш техникасын һәм шәхси кулланылыш предметларын ремонтлау | | - " - | 2,0 | - " - | - " - | - " - | - " - |
| - металл әйберләрен ремонтлау һәм әзерләү | | - " - | 1,0 | - " - | - " - | - " - | - " - |
| - машиналарны, җиһазларны һәм приборларны, оештыру техникасын һәм периферия җайланмаларын ремонтлау | | - " - | 2,0 | - " - | - " - | - " - | - " - |
| - автотранспорт чараларына сервис хезмәте күрсәтү | | - " - | 2,0 | - " - | - " - | - " - | - " - |
| - фото-, кино хезмәтләрен күрсәтү, моңа кинофильмнар прокаты керми | | - " - | 1,5 | - " - | - " - | - " - | - " - |
| - прокат | | - " - | 0,5 | - " - | - " - | - " - | - " - |
| - халыкка башка төрле көнкүреш хезмәте күрсәтү | | - " - | 1,5 | - " - | - " - | - " - | - " - |

*3 нче кушымта*

| Эшчәнлек өлкәләре | Эшчәнлекнең шушы төрен характерлаучы физик күрсәткечләр (N) | Физик күрсәткеч берәмлегенең база керемлелеге, елына бер берәмлеккә сумнарда (C) | Эшчәнлекнең икенчел төрләренә арттыручан (киметүчән) коэф. (Д) | Торак пункты тибына арттыручан (киметүчән) коэффициент (E) | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Казан | республика буйс. шәһәрләр | район буйс. шәһәрләр | башка торак пунктлары |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| Физик затларга түбәндәге хезмәтләрне күрсәтү: | Эшләүче белгечләр саны | 14600 | 1,0-1,5 | 1,0 | 0,8 | 0,7 | 0,4 |
| - чәчтараш, косметологик (шул исәптән косметик салоннарда) | | - " - | 1,5 | 1,0 | - " - | - " - | - " - |
| - медицина | | - " - | 1,0 | 1,0 | - " - | - " - | - " - |
| - ветеринария | | - " - | 1,5 | 1,0 | - " - | - " - | - " - |
| - зоохезмәт күрсәтүләр | | - " - | 1,0 | 1,0 | - " - | - " - | - " - |
| - индивидуаль эшкуарларның хезмәт күрсәтүе | Гомуми мәйданы (кв.м) | 210 | 1,0 | - " - | - " - | - " - | - " - |
| - аз вакытка килүчеләр өчен | | - " - | 1,0 | 1,0 | - " - | - " - | - " - |
| - индивид.эшкуарларның хезмәт күрсәтүләре | Эшләүче белгечләр саны | 60000 | 0,2-1,0 | 1,0 | - " - | - " - | - " - |
| - консультацияләр | | - " - | 1,0 | 1,0 | - " - | - " - | - " - |
| - бухгалтер хезмәтләре | | - " - | 1,0 | 1,0 | - " - | - " - | - " - |
| - юридик хезмәтләр | | - " - | 0,8 | 1,0 | - " - | - " - | - " - |
| - аудитор хезмәтләре | | - " - | 1,0 | 1,0 | - " - | - " - | - " - |
| - өйрәтү, репетиторлык, мөгаллимлек һәм мәгариф өлкәсендә башка төрле эшчәнлек | | - " - | 0,2 | 1,0 | - " - | - " - | - " - |

| Эшчәнлек өлкәләре | Җәмәгать туклануы | Кафе, бар, кабымлык | | Ресторан, чәркәханә | Ашханә | Балалар өчен җәмәгать туклануы нокталары | Килүчеләр өчен утырыр урыннары булмаган җәмәгать туклануы урыннары | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | алког. эчемлекләр белән | алкоголь сез эчемлекләр белән | | | | алког. эчемлекләр белән | алкогольсез эчемлекләр белән |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| Әлеге эшчәнлек төрен характерлаучы натураль күрсәткечләр (№) | Хуҗалык эшчәнлегендә кулланылучы бер утырыр урынга | | | | | | | |
| Физик күрсәткеч берәмлегенең база керемлелеге, елына бер берәмлеккә сумнарда (С) | 5006 | | | | | | 15600 | 15600 |
| Арттыручан (киметүчән) коэффициент | | | | | | | | |
| Эшчәнлекнең иярчен төрләре (Е) | | 1,3 | 1,0 | 2,0 | 1,0 | 1,0 | 1,3 | 1,0 |
| Өстәмә инфраструктурадан файдалану мөмкинлеге: (G) | | | | | | | | |
| - дискотека, дансинг, танц-пол, варьете, оркестр, караоке | | 1,2 | 1,2 | 1,3 | 1,3 | 1,2 | - | - |
| - уен автоматлары | | 1,3 | 1,3 | 1,3 | 1,3 | 1,2 | - | - |
| - казино | | 1,5 | 1,5 | 1,5 | 1,5 | - | - | - |
| - бильярд һәм өстәмә эшчәнлекнең бүтән төрләре | | 1,3 | 1,3 | 1,3 | 1,3 | - | - | - |
| Комплекслы хезмәт күрсәтүләр | | 1,5 | 1,5 | 1,5 | 1,5 | 1,0 | - | - |
| Күрсәтелүче хезмәтләрнең сыйфаты: өстәмә бәяләр белән (J) | | | | | | | | |
| 30%ка кадәр | | 1,0 | 1,0 | 1,0 | 1,0 | 1,0 | 1,0 | 1,0 |
| 30%тан 70%ка кадәр | | 1,2 | 1,2 | 1,2 | 1,2 | - | 1,2 | 1,2 |
| 70%тан 100%ка кадәр | | 1,3 | 1,3 | 1,3 | 1,3 | - | 1,3 | 1,3 |
| 100% тан 150%ка кадәр | | 1,5 | 1,5 | 1,5 | 1,5 | - | 1,5 | 1,5 |
| 150% тан | | 3,0 | 3,0 | 3,0 | 3,0 | - | 3,0 | 3,0 |
| Торак пункты тибына арттыручан (киметүчән) коэффициент (Е) | | | | | | | | |
| - Казан | | 1,0 | 1,0 | 1,0 | 1,0 | 1,0 | 1,0 | 1,0 |
| -республика буйсынуындагы шәһәрләр | | 0,8 | 0,8 | 0,8 | 0,8 | 0,8 | 0,8 | 0,8 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| -район буйсынуындагы шәһәрләр | | 0,7 | 0,7 | 0,7 | 0,7 | 0,7 | 0,7 | 0,7 |
| - башка төрле торак пунктлары | | 0,4 | 0,4 | 0,4 | 0,4 | 0,4 | 0,4 | 0,4 |
| Тәүлеклек коэф. (F) | | 1,5 | - | 1,5 | - | - | 1,5 | - |

Искәрмә: Өстәмә инфраструктурадан файдалану мөмкинлеге буенча (G) берничә коэффициент кулланган очракта, аларның нәтиҗәдәге зурлыгы 1,5 тән артмаска тиеш.

*5 нче кушымта*

| Эшчәнлек өлкәләре | Эшчәнлекнең шушы төрен характерлаучы физик күрсәткечләр (N) | Физик күрсәткеч берәмлегенең база керемлелеге, елына бер берәмлеккә сумнарда (С) | Эшчәнлекнең икенчел төрләренә арттыручан (киметүчән) коэф. (Д) | Тәүлеклек (F) | Торак пункты тибына арттыручан (киметүчән) коэф. (Е) | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Казан | республика буйс. шәһәрләр | район буйс. шәһәрләр | башка торак пунктлары |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| Эшләүчесе 30 кешегә кадәр булган кибетләр аша, палаткалар, лареклар, сәүдә павильоннары аша һәм, сәүдә мәйданнары булмаган стационар сәүдә оештыру урыннарыннан тыш, башка стационар сәүдә оештыру урыннары аша түбәндәгеләр буенча ваклап сату итү: | Хуҗалык эшчәнлегендә файдаланылучы гомуми сәүдә (кв.м) | 7314 | 0,6-2,0 | 1,2-1,5 | 1,0 | 0,8 | 0,7 | 0,4 |
| көйләүле бәяләр буенча сатылучы азык-төлек продуктлары; | искәрмә: 300 кв.м.дан артып киткән мәйданнан 0,5кә тигез киметүчән коэф. кулланыла | - " - | 0,6 | 1,2 | - " - | - " - | - " - | - " - |
| - азык-төлек продуктлары | | - " - | | 1,5 | - " - | - " - | - " - | - " - |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| (спиртлы эчемлекләрсез); | | | 1,3 | 1,2 | - " - | - " - | - " - | - " - |
| - спиртлы эчемлекләр; | | - " - | 2 | 1,5 | - " - | - " - | - " - | - " - |
| - куәтләндерелмәгән һәм аз куәтләндерелгән эчемлекләр | | - " - | 1,4 | 1,3 | - " - | - " - | - " - | - " - |
| - тәмәке әйберләре һәм шуларга ияртчен товарлар; | | | | | | | | |
| - ирләр һәм хатын-кызлар киемнәре, аяк киемнәре, эчке киемнәр, тукыма; | | - " - | | | - " - | - " - | - " - | - " - |
| - фурнитура, сәгатьләр; | | | 1,0 | 1,0 | | | | |
| - хуҗалык товарлары, көнкүреш химиясе, төзелеш материаллары; | | - " - | 1,7 | 1,0 | | | | |
| - күн, мех киемнәре; | | - " - | 1,4 | 1,0 | - " - | - " - | - " - | - " - |
| - балалар киемнәре; | | - " - | 1,0 | 1,0 | - " - | - " - | - " - | - " - |
| - көнкүреш техникасы, электр товарлары; | | - " - | 2,0 | 1,0 | - " - | - " - | - " - | - " - |
| - җиһазлар һәм оештыру техникасы; | | - " - | 2,0 | 1,0 | - " - | - " - | - " - | - " - |
| - автомобильләр һәм аларга запас частьләр; | | - " - | 1,8 | 1,0 | - " - | - " - | - " - | - " - |
| - видеокассеталар, аудиокассеталар, компакт-дисклар; | | - " - | 2,0 | 1,0 | - " - | - " - | - " - | - " - |
| - өй җиһазлары (мебель), келәмнәр; | | - " - | 1,0 | 1,0 | - " - | - " - | - " - | - " - |
| - канцтоварлар; | | - " - | 1,3 | 1,0 | - " - | - " - | - " - | - " - |
| - китаплар, полиграфия әйберләре; | | - " - | 1,0 | 1,0 | - " - | - " - | - " - | - " - |
| - парфюмерия; | | - " - | 1,3 | 1,0 | - " - | - " - | - " - | - " - |
| - медикаментлар һәм медицина билгеләнешендәге товарлар; | | - " - | 0,6 | 1,0 | - " - | - " - | - " - | - " - |
| - күп профильле һәм бүтән төр сәүдә | | - " - | 1,5 | 1,3 | - " - | - " - | - " - | - " - |

| Эшчәнлек өлкәләре | Эшчәнлекнең шушы төрен характерлаучы физик күрсәткечләр (N) | Физик күрсәткеч берәмлегенең база керемлелеге, елына бер берәмлеккә сумнарда (С) | Эшчәнлекнең икенчел төрләренә арттыручан (киметүчән) коэф. (Д) | Торак пункты тибына арттыручан (киметүчән) коэф. (Е) | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Казан | республика буйс. шәһәрләр | район буйс. шәһәрләр | башка торак пунктлары |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| Базарларда, стационар булмаган бүтән сәүдә итү урыннарында (ачык прилавкалардан, лотоклардан сату), сәүдә мәйданнары булмаган стационар сәүдә урыннарында эшкуарлар һәм оешмалар тарафыннан түбәндәгеләр буенча ваклап сату итү: | Бер сәүдә итү урыны | 15600 | 1,0-2,0 | 1,0 | 0,8 | 0,7 | 0,4 |
| - балалар өс киемнәре һәм аяк киемнәре; | | - " - | 1,0 | - " - | - " - | - " - | - " - |
| - китаплар, полиграфия әйберләре; | | - " - | 1,0 | - " - | - " - | - " - | - " - |
| - канцелярия әйберләре; | | - " - | 1,0 | - " - | - " - | - " - | - " - |
| - газеталар, журналлар; | | - " - | 1,0 | - " - | - " - | - " - | - " - |
| - азык-төлек продуктлары; | | | | | | | |
| - аудио-,видеокассеталар; | | - " - | 1,5 | - " - | - " - | - " - | - " - |
| - өй җиһазлары (мебель), келәмнәр; | | - " - | 1,5 | - " - | - " - | - " - | - " - |
| - аяк киемнәре, өс киемнәре, эчке киемнәр, тукымалар; | | - " - | 1,5 | - " - | - " - | - " - | - " - |
| - көнкүреш техникасы, аудио-, видеотехника; | | - " - | 1,5 | - " - | - " - | - " - | - " - |
| - автомобильләр һәм аларга запас частьләр; | | - " - | 1,5 | - " - | - " - | - " - | - " - |
| - күн, замша, мех әйберләре; | | - " - | 1,5 | - " - | - " - | - " - | - " - |
| - бүтән куллану әйберләре; | | - " - | 1,3 | - " - | - " - | - " - | - " - |
| - азык-төлек продуктлары (алкоголь белән) | | - " - | 1,5 | - " - | - " - | - " - | - " - |
| - алкогольле продукция | | - " - | 2,0 | - " - | - " - | - " - | - " - |
| - катнаш сәүдә | | - " - | 1,5 | - " - | - " - | - " - | - " - |

| Эшчәнлек өлкәләре | Әлеге төр эшчәнлекне тасвирлаучы физик күрсәткечләр (N) | Физик күрсәткеч берәмлегенең база керемлеге, елына бер берәмлеккә сумнарда (С) | Эшчәнлек төрләренең арттыручан (киметүчән) коэффициентлары (Д) | Реализацияләнә торган ЯММ ассортиментын исәпкә алучы арттыру (киметү) коэффициентлары (Z) | Эшнең тәүлекле коэффициенты | Торак пункт тибы буенча арттыручан (киметүчән) коэффициентлар (Е) | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Казан | республика буйсынуындагы шәһәрләр | район буйсынуындагы шәһәрләр | бүтән төрле торак пунктлары |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| Ягулык-майлау материалларын ваклап сату | | | 1,0 | 1,1 | 1,1 | 1,0 | 0,8 | 0,7 | 0,4 |
| - традицион АЯСлар өчен | 1 ягулык тарату колонкасы | 420000 | 1,0 | 1,1 | 1,1 | -"- | -"- | -"- | -"- |
| - читкә чыгып (стационар булмаган) сәүдә итүнең модульле һәм контейнерлы АЯСлары | резервуарның (камераның) 1 куб.метры | 150000 | 1,0 | 1,1 | 1,1 | -"- | -"- | -"- | -"- |

Искәрмә: 7 графадагы торак пунктлар тибына карата арттыручан (киметүчән) коэффициентлар торак пунктларында күрсәтелгән АЯСлар өчен дә, юл буйларында яки федераль әһәмияттәге магистральләрнең юл буйларыннан 150 м га кадәр читтә урнашкан АЯСлар өчен дә, 8 графадагы юл буйларында урнашкан йә республика әһәмиятендәге II-IV категориядәге магистральләрнең юл буйларыннан 150м га кадәр читтә урнашкан АЯСлар өчен дә кулланыла. Башка юлларның юл буйларында йә юл буйларыннан 150 м га кадәр араны кертеп урнашкан АЯСлар өчен 0,7 коэффициенты кулланыла. Район буйсынуындагы шәһәрләрдә урнашкан АЯСлар өчен 9 графадагы коэффициент, бүтән торак пунктларда

*8 нче кушымта*

| Эшчәнлек өлкәләре | Әлеге төр эшчәнлекне тасвирлаучы физик күрсәткечләр (N) | Физик күрсәткеч берәмлегенең база керемлеге, ел берәмлегенә рубльләрдә (С) | Эшчәнлек төрләренең арттыручан (киметүчән) коэффициентлары (Д) | Эшнең тәүлеклелек коэф. | Автотранспорт чаралары паркының арттыручан (киметүчән) коэф. | | | Торак пункт тибы буенча арттыручан (киметүчән) коэффициентлар (Е) | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 1 дән 5 кә кадәр | 5 тән 15 кә кадәр | 15 тән һәм аннан югарырак | Казан | р-ка буйс. шәһәрләр | район. буйс. шәһәрләр | бүтән төрле торак пунктлары |
| | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| Эшкуарлар һәм 100 кешегә кадәр эшләүчесе булган оешмалар тарафыннан автотранспорт хезмәтләре күрсәтү (маршрут таксиларында коммерциячел нигездә пассажирлар йөртү хезмәтеннән гайре) | Транспорт чарасының бер берәмлеге | 43100 | 0,8-1,5 | 1,2-1,0 | 2 | 1,5 | 1 | 1,0 | 0,8 | 0,7 | 0,4 |
| жиңел транспорт | | - " - | 1,0 | 1,2 | 2 | 1,5 | 1 | -"- | - " - | - " - | - " |
| автобус | | - " - | 0,8 | 1,0 | 2 | 1,5 | 1 | -"- | - " - | - " - | - " |
| йөк автотранспорты | | - " - | 1,0 | 1,0 | 2 | 1,5 | 1 | -"- | - " - | - " - | - " |
| Маршрут таксиларында коммерциячел нигездә пассажирлар йөртү хезмәтләрен күрсәтү | | 43100 | 1,5 | 1,2 | 2 | 1,5 | 1 | -"- | - " - | - " - | - " |

| Эшчәнлек өлкәләре | Әлеге төр эшчәнлекне тасвирлаучы физик күрсәткечләр (N) | Физик күрсәткеч берәмлегенең база керемлелеге, елына бер берәмлеккә сумнарда (С) | Эшчәнлек төрләренең арттыручан (киметүчән) коэффициентлары (Д) | Торак пункт тибы буенча арттыручан (киметүчән) коэффициентлар (Е) | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Казан | республика буйсынуындагы шәһәрләр | район буйсынуындагы шәһәрләр | бүтән төрле торак пунктлары |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| Түбәндәгеләрне тәкъдим иткән өчен хезмәтләр күрсәтү: | Хуҗалык эшчәнлегендә файдаланылучы гомуми мәйдан (кв.м) | 285 | 1,0-2,0 | 1,0 | 0,8 | 0,7 | 0,4 |
| автомобиль куеп тору урыннарын | | | 1,0 | - " - | - " - | - " - | - " - |
| автомобильләрне куеп тору өчен түбәсе ябык урыннарны, гаражларны | | | 2,0 | - " - | - " - | - " - | - " - |

10 нчы кушымта

# ЙӨКЛӘНГӘН КЕРЕМНӘН ______ ЕЛНЫҢ __________ КВАРТАЛЫНДА ТҮЛӘНЕРГӘ ТИЕШЛЕ БЕРЛӘШКӘН САЛЫМ ИСӘП-ХИСАБЫ

Салым түләүченең исеме ______________________________

Урнашкан урыны ______________________________

Хезмәт күрсәтүче банкларның исеме, аларның урнашкан урыны, счетлар номеры ______________

______________________________

| Т/с | Эшчәнлектәре | Эшләүчеләр саны | Урнашкан урыны | Физик күрсәткечләр исеме | Үлчәү берәмлеге | Физик күрсәткечләр күләме | Физик күрсәткеч берәмлегенең база керемлеге | Арттыручан (киметүчән) коэффициентлар | | | | | | Реализацияләнүче ГСМ ассортиментын исәпкә алучы коэф. (L) | Берләшкән керем күләме сум. 7 гр х 8 гр 9 гр | Берләшкән керем ставкасы | Берләшкән керем суммасы, сум, 16 гр х 17:100 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | Эшчәнлекнең нәрчен төрләрен исәпкә алучы коэф. (Д) | Торак пунктын исәп. Алучы коэф.(Е) | Эшнең төүлеклек коэф. (F) | Өстәмә инфраструктурадан файд.мөмк. коэф. (G) | Күрсәтелүче хезмәтләрне исәп алучы коэф. (J) | Авто-транс. паркын коррек-ирлаштыручы коэф. (K) | | 10 гр х 11 гр х 12 гр х 13 гр х 14 гр х 15 гр х | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | Барысы | | | | | | | | | | | | | | | | |

Оешма җитәкчесе
(эшкуар) ______________ ______________________
(имза) (Ф.И.Ат.и.)

м.у.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 771. «2000-2005 елларга йогышлы авыруларны вакцина белән профилактикалау» республика максатчыл программасы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тәкъдим иткән «2000-2005 елларга йогышлы авыруларны вакцина белән профилактикалау» республика максатчыл программасын расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты чираттагы финанс елына һәм, 2005 елны да кертеп, аннан соңгы елларга Татарстан Республикасының республика бюджетын төзегәндә әлеге программаны аерым юл белән финанслауны күздә тотарга тиеш.

3. «2000-2005 елларга йогышлы авыруларны вакцина белән профилактикалау» республика максатчыл программасының үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль мәсьәләләр һәм яшьләр эшләре комиссиясенә йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 17 ноябре
№ 2431

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 772. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 1 декабрендәге утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 1 декабрендәге утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. «Татарстан Республикасының аерым район, шәһәр судлары судьяларын сайлау һәм рәисләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

2. «Кама Аланы» махсус икътисадый зонасы турында» Татарстан Республикасы законын кабат карау хакында.

3. «Экологик экспертиза турында» Татарстан Республикасы законын кабат карау хакында.

4. «Татарстан Республикасы гражданнарының хокук тәртибен тәэмин итүдә катнашуы турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

5. «Наркотик чараларның һәм психотрон матдәләрнең законсыз әйләнешенә һәм кулланылышына бәйле хокук бозулар өчен административ җаваплылык турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

6. «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

7. «Санитар хокук бозулар өчен административ җаваплылык турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

8. «Халыкның санитар-эпидемия иминлеге турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

9. «Халыкны туберкулездан яклау һәм туберкулезга каршы ярдәм турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

10. «Авыл хуҗалыгы җирләре залогы турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

11. «Гадәттән тыш хәлләрдә иминлек турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

12.«Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлекләрен сату-алу турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

13. «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» Федераль законның 24 статьясына өстәмә кертү хакында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

14. «Җәмәгать тәртибен һәм идарә итү тәртибен бозган өчен административ җаваплылык турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә кертү тәртибе хакында» Татарстан Республикасы Югары Советының 1993 елның 18 маендагы 1858-XII номерлы карарына үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

15. «Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы халык депутатларының кагылгысызлыгын тәэмин итү өлешендә Татарстан Республикасы Конституциясенең һәм «Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советы халык депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законының «Татарстан Республикасы Прокуратурасы тарафыннан үтәлеше турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 20 маендагы карарын үтәүнең барышы хакында.

16. Россия Федерациясенең Федераль Җыелышы Дәүләт Думасының Ветераннар эшләре буенча комитетының, Мәскәү өлкәсе хезмәт ветераннарының район, Кораллы Көчләр һәм хокук саклау органнары ветераннарының җәмәгать оешмаларының Россия Федерациясе Президентына, Россия Федерациясе Федераль Җыелышының Федерация Советы Рәисенә, Россия Федерациясе Федераль Җыелышының Дәүләт Думасы Рәисенә, Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисенә, Россия Федерациясе субъектларының закон чыгару һәм башкарма хакимияте органнары җитәкчеләренә Россия Федерациясе ветераннарын хокукый һәм социаль яклауга карата дәүләт сәясәтен булдыру турындагы мөрәҗәгате хакында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты турында.

17. «Автотранспорт чараларын тротуарлар янында парковкалауны тәртипкә салу гамәлләре турында» Казан шәһәре администрациясе башлыгының 1998 елның 7 сентябрендәге 1801 нче карары хакында.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 1 декабре
№ 2451

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 773. Татарстан Республикасының аерым район, шәһәр судлары судьяларын сайлау һәм рәисләрен раслау турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 89 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Судьялар итеп сайларга:

Татарстан Республикасының Әлмәт шәһәр судына:

Газетдинов Мөхәммәди Таҗи улын һәм аны, Татарстан Республикасының Норлат район суды судьясы вазыйфаларыннан азат итеп, әлеге суд рәисе итеп расларга;

Мирсаяпов Илдар Тәлгать улын, әлеге суд рәисе вазыйфаларыннан азат итеп;

Казан шәһәренең Вахитов район судына

Баһавова Рузалия Кыям кызын;

Татарстан Республикасының Лаеш район судына

Ширшлина Фәния Кираметдин кызын;

Татарстан Республикасының Минзәлә район судына
Тыгин Рөстәм Мирлатыйф улын;
Татарстан Республикасының Мөслим район судына
Билалов Эрдуль Зиннур улын һәм аны, Татарстан Республикасының Сарман район суды судьясы вазыйфаларыннан азат итеп, әлеге суд рәисе итеп расларга;
Татарстан Республикасының Норлат район судына
Гыйльманов Альфис Салихҗан улын һәм аны әлеге суд рәисе итеп расларга;
Казан шәһәренең Идел буе район судына
Йосыпов Җәүдәт Хәйрулла улын, аны Татарстан Республикасының Минзәлә район суды судьясы вазыйфаларыннан азат итеп;
Татарстан Республикасының Сарман район судына
Салихов Марсель Фәис улын.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 1 декабре
№ 2452

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 774. «Халыкны туберкулездан саклау һәм туберкулезга каршы ярдәм турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Халыкны туберкулездан саклау һәм туберкулезга каршы ярдәм турында» Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

2. «Халыкны туберкулездан саклау һәм туберкулезга каршы ярдәм турында» Татарстан Республикасы законы проектын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе катнашында, мөмкин булган эчке юридик каршылыкларны бетерү, статьяларның үзара дөрес бәйләнешен билгеләү, Татарстан Республикасы Конституциясенә туры китерү өчен, Социаль мәсьәләләр һәм яшьләр мәнфәгатьләре комиссиясенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 1 декабре
№ 2453

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 775. «Авыл хуҗалыгы җирләрен залогка салу турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Авыл хуҗалыгы җирләрен залогка салу турында» Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

2. . «Авыл хуҗалыгы җирләрен залогка салу турында» Татарстан Республикасы законы проектын, мөмкин булган эчке юридик каршылыкларны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе катнашында бетерү, статьяларның үзара дөрес бәйләнешен билгеләү, Татарстан Республикасы Конституциясенә туры китерү өчен, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисадый үсеш һәм реформа мәсьәләләре комиссиясенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 1 декабре
№ 2454

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 776. «Гадәттән тыш хәлләрдә иминлек турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Гадәттән тыш хәлләрдә иминлек турында» Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә һәм, төзәтмәләр рәвешендә бирелгән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне исәпкә алып, аны эшләүне дәвам итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр 2000 елның 1 гыйнварена кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экологик иминлек мәсьәләләре, табигый байлыклар һәм табигатьтән файдалану мәсьәләләре комиссиясенә кертелә, дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экологик иминлек мәсьәләләре, табигый байлыклар һәм табигатьтән

файдалану мәсьәләләре комиссиясе күрсәтелгән закон проектын, кергән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне исәпкә алып, 2000 елның 1 февраленә кадәр эшләп бетерергә һәм икенче укылышта карау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тәкъдим итәргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 1 декабре
№ 2455

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 777. «Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлекләрен сату-алу турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлекләрен сату-алу турында» Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә һәм, төзәтмәләр рәвешендә бирелгән тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне исәпкә алып, аны эшләүне дәвам итәргә.

2. Әлеге закон проектына төзәтмәләрне 2000 елның 1 гыйнварена кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисадый үсеш һәм реформалар мәсьәләләре комиссиясенә җибәрергә, дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисадый үсеш һәм реформалар мәсьәләләре комиссиясе, кертелгән искәрмәләре һәм тәкъдимнәрне исәпкә алып, әлеге Закон проектын 2000 елның 1 февраленә кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 1 декабре
№ 2456

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 778. «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» Федераль законның 24 статьясына өстәмә кертү хакында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында

Россия Федерациясе Конституциясенең 104 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. Закон чыгару инициативасы тәртибендә Россия Федерациясенең Федераль Җыелышы Дәүләт Думасына «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» Федераль законның 24 статьясына өстәмә кертү хакында» федераль закон проекты кертергә (кушымта итеп бирелә).

2. Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнарыннан әлеге федераль закон проектын хуплауларын сорарга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшинга йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 1 декабре
№ 2457

*Татарстан Республикасы Дәүләт Советының*
*1999 елның 1 декабрендәге*
*2457нче карарына кушымта*

*Проект Татарстан Республикасы Дәүләт Советы*
*тарафыннан кертелә*

## «ХӘРБИ БУРЫЧ ҺӘМ ХӘРБИ ХЕЗМӘТ ТУРЫНДА» ФЕДЕРАЛЬ ЗАКОННЫҢ 24 СТАТЬЯСЫНА ӨСТӘМӘ КЕРТҮ ХАКЫНДА

ФЕДЕРАЛЬ ЗАКОН

Дәүләт Думасы _______ кабул итте
Федерация Советы_______ хуплады

1 статья. «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» Федераль законның 24 статьясына (Россия Федерациясенең Законнар җыентыгы, 1998, № 13, 1475 бит) түбәндәге өстәмәне кертергә:

24 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле и) пунктчасы өстәргә:

«и) крестьян (фермер) хуҗалыгы алып баручы, крестьян (фермер) хуҗалыгы алып баруда катнашучы һәм гаиләдә бердәнбер ул булып торучы гаилә әгъзаларына».

2 статья. Әлеге Федераль закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Россия Федерациясе Президенты**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 779. «Җәмәгать тәртибен һәм идарә итү тәртибен бозган өчен административ җаваплылык турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә кертү тәртибе хакында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1993 елның 18 маендагы 1858-XII номерлы карарына үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Закон чыгару, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре ко-

миссиясе тәкъдимен исәпкә алып, «Җәмәгать тәртибен һәм идарә итү тәртибен бозган өчен административ җаваплылык турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә кертү тәртибе хакында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1993 елның 18 маендагы 1858-XII номерлы карарына үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проектын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравыннан төшереп калдырырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 1 декабре
№ 2458

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 780. «Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы халык депутатларының кагылгысызлыгын тәэмин итү өлешендә Татарстан Республикасы Конституциясенең һәм «Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советы халык депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законының «Татарстан Республикасы Прокуратурасы тарафыннан үтәлеше хакында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 20 маендагы карары үтәлешенең барышы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советына «Татарстан Республикасы халык депутаты статусы турында» һәм «Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советы халык депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы законнарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты кертелүгә бәйле рәвештә, күрсәтелгән карарның үтәлеше турындагы мәсьәләне Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравыннан төшереп калдырырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 1 декабре
№ 2459

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 781. «Хокук тәртибен тәэмин итүдә Татарстан Республикасы гражданнарының катнашуы турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

«Хокук тәртибен тәэмин итүдә Татарстан Республикасы гражданнарының катнашуы турында» Татарстан Республикасы законы проектын Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елгы көзге сессиясе каравыннан төшереп калдырырга һәм аны, өченче укылышка әзерләү режимында эшләүне дәвам итү өчен, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Закон чыгару, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре комиссиясенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 1 декабре
№ 2460

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 782. Россия Федерациясенең Федераль Җыелышы Дәүләт Думасының Ветераннар эшләре буенча комитетының, Мәскәү өлкәсе хезмәт ветераннарының, район, Кораллы Көчләр һәм хокук саклау органары ветераннарының җәмәгать оешмаларының Россия Федерациясе Президентына, Россия Федерациясе Федераль Җыелышының Федерация Советы Рәисенә, Россия Федерациясе Федераль Җыелышының Дәүләт Думасы Рәисенә, Россия Федерацисе Хөкүмәте Рәисенә, Россия Федерацисе субьектларының закон чыгару һәм башкарма хакимият органнары җитәкчеләренә Россия Федерациясе ветераннарын хокукый һәм социаль яклауга карата дәүләт сәясәтен булдыру турындагы мөрәҗәгате хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. Россия Федерациясенең Федераль Җыелышы Дәүләт Думасының Ветераннар эшләре комитетының, Мәскәү өлкәсе хезмәт ветераннарының, район, Кораллы Көчләр һәм хокук саклау органары ветераннарының җәмәгать оешмаларының Россия Федерациясе Президентына, Россия Федерациясе Федераль Җыелышының Федерация Советы Рәисенә, Россия Федерациясе Федераль Җыелышының Дәүләт Думасы Рәисенә, Россия Федерацисе Хөкүмәте Рәисенә, Россия Федерацисе субьектларының закон чыгару һәм башкарма хакимият органнары җитәкчеләренә Россия Федерациясе ветераннарын хокукый һәм социаль яклауга карата дәүләт сәясәтен булдыру турындагы мөрәҗәгатен хупларга.

2. Єлеге мөрәҗәгатьне Россия Федерациясенең Федераль җыелышы Дәүләт Думасының Россия Федерациясе Президентына һәм Россия Федерацисе Хөкүмәтенә сугыш һәм хезмәт ветераннарына алар 1991 елның 20 июненә кадәр Россия Федерациясе саклык банкы учрежденияләренә керткән кертемнәрне

компенсацияләү түләүне тизләтү буенча нәтиҗәне чаралар күрүне тәгъдим итәү белән тулыландыруны тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль җыелышының Дәүләт Думасының Ветереннар эшләре комитетына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елнын 1 декабре
№ 2461

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 783. «Автотранспорт чараларын тротуарлар янында парковкалауны тәртиптә салу чаралары турында» Казан шәһәре администрациясе башлыгының 1998 елның 7 сентябрендәге 1801 нче карары хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Казан шәһәре администрациясе башлыгы К.Ш.Исхаковның әлеге мәсьәлә буенча мәгълүматын игътибарга алырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 1 декабре
№ 2462

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 784. «Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының төзәтү эшләре һәм социаль реабилитацияләү хезмәте эшчәнләген камилләштерү чаралары турында» Татарстан Республикасы Президенты Указын гамәлгә ашыруның барышы хакында» Татарстан Республикасы халык депутаты И.С. Абдуллин таләбе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының төзәтү эшләре һәм социаль реабилитацияләү хезмәте эшчәнләгеен ка-

милләштерү чаралары турында» Татарстан Республикасы Президенты Указын гамәлгә ашыруның барышы хакында» Татарстан Республикасы халык депутаты И.С. Абдуллин таләбенә җавапны игътибарга алырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 1 декабре
№ 2463

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 785. «Суд яклавына хокукны (Татарстан Республикасы Конституциясенең 33 статьясы) гамәлгә ашыру һәм дәүләт хакимиятен дискредитацияләү турында» Татарстан Республикасы халык депутаты С.К.Осколок таләбе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

«Суд яклавына хокукны (Татарстан Республикасы Конституциясенең 33 статьясы) гамәлгә ашыру һәм дәүләт хакимиятен дискредитацияләү турында» Татарстан Республикасы халык депутаты С.К.Осколок таләбенә җавапны игътибарга алырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 1 декабре
№ 2464

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 786. «Татарстан Республикасы Конституциясенең 104 статьясын үтәү турында» Татарстан Республикасы халык депутаты С.К. Осколок таләбе хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

«Татарстан Республикасы Конституциясенең 104 статьясын үтәү турында» Татарстан Республикасы халык депутаты С.К. Осколок таләбенә җавапны игътибарга алырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 1 декабре
№ 2465

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 787. «Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча җәзаларны үтәү идарәсенә салым ташламалары бирү турында» Татарстан Республикасы халык депутаты В.Н. Чубаренко таләбе хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

«Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча җәзаларны үтәү идарәсенә салым ташламалары бирү турында» Татарстан Республикасы халык депутаты В.Н. Чубаренко таләбенә җавапны игътибарга алырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 1 декабре
№ 2466

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 788. «Кече эшкуарлыкка булышлык итү өлешендә Татарстан Республикасы бюджет законнарының үтәлмәве турында» Татарстан Республикасы халык депутаты С.А.Брусов таләбе хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

«Кече эшкуарлыкка булышлык итү өлешендә Татарстан Республикасы бюджет законнарының үтәлмәве турында» Татарстан Республикасы халык депутаты С.А.Брусов таләбенә җавапны игътибарга алырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 1 декабре
№ 2467

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 789. Татарстан Республикасы кулланучыларын ягулык-энергетика ресурслары белән тәэмин итү чаралары турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы кулланучыларын ягулык-энергетика ресурслары белән тәэмин итү чаралары турында Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Ягулык кытлыгы килеп туганда Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

- Татарстан Республикасы кулланучылары өчен энергия белән беренче категориядә тәэмин ителүче халыкка һәм кулланучыларга энергия бирүнең сакланышын күздә тотучы чикләүләр (өзүләр) графикларын расларга;

- сәнәга предприятиеләре һәм оешмалары тарафыннан энергия ресурсларын куллану һәм кулланган энергия ресурслары өчен тулысынча түләү буенча кичектергесез чаралар күрергә;

- нефть ятмаларының ташкүмерле катламнарын яндырып тәҗрибә-сәнәга сынаулары үткәрүне исәпкә алып, нефть ятмаларының ташкүмерле катламнарыннан файдалануны да кертеп, энергия чыганакларының альтернатив төрләреннән, шул исәптән җил энергиясеннән дә, файдалану программасын эшләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 1 декабре
№ 2468

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 790. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме беренче пленар сессиясе көн тәртибенә өстәмә мәсьәләләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме беренче пленар сессиясе көн тәртибенә түбәндәге өстәмә мәсьәләләрне кертергә:

1. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарын һәм аның урындагы затларын сайлаулар турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).

2. «Татарстан Республикасында юллар фонды турында»

Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

3. «Татарстан Республикасы халык депутатлары вәкилләре киңәшмәсе турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты турында.

4. «Татарстан Республикасы халык депутаты М.Ш.Хөсәеновны Татарстан Республикасы Дәүләт Советында даими нигездә эшләүдән азат итү турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

5. «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабат карау турында.

6. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1995 елның мартыннан 1999 елның декабренә кадәр чордагы эшчәнлеге турында мәгълүмат.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 6 декабре
№ 2477

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 791. Татарстан Республикасы халык депутатлары вәкилләренең киңәшмәсе турында нигезләмәне раслау хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы халык депутатлары вәкилләренең киңәшмәсе турында нигезләмәне расларга (кушымта итеп бирелә).

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 6 декабре
№ 2478

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 792. Татарстан Республикасы халык депутаты М.Ш.Хөсәеновны Татарстан Республикасы Дәүләт Советында даими нигездә эшләүдән азат итү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы халык депутаты Мөнир Шириаздан улы Хөсәеновны Татарстан Республикасы Дәүләт Советында даими нигездә эшләүдән азат итәргә.

2. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советында даими нигездә эшләүче Татарстан Республикасы халык депутатлары составы турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1995 елның 26 апрелендәге аннан соңгы үзгәрешләр белән карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

2 пунктта:

| | |
|---|---|
| «Хөсәенов Мөнир Шириаздан улы | 127 нче Мишә территория сайлау округы» |

дигән сүзләрне төшереп калдырырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 6 декабре
№ 2479

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 793. «Кулланучыларга кайнар һәм салкын су бирү нормалары һәм тарифлары турында» Татарстан Республикасы халык депутаты Н.Ф.Әбдрәшитова таләбе хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

«Кулланучыларга кайнар һәм салкын су бирү нормалары һәм тарифлары турында» Татарстан Республикасы халык депутаты Н.Ф.Єбдрәшитова таләбенә җавапны игътибарга алырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 6 декабре
№ 2480

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 794. «Татарстан Республикасы гражданнарын дарулар белән тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы халык депутаты Ф.Ш.Сафиуллин таләбе хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

«Татарстан Республикасы гражданнарын дарулар белән

тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы халык депутаты Ф.Ш.Сафиуллин таләбенә җавапны игътибарга алырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 6 декабре
№ 2481

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 795. «Зеленодол шәһәре эчке эшләр идарәсенең гражданнар мөрәҗәгатьләрен караганда законнарны үтәве турында» Татарстан Республикасы халык депутаты С.К.Осколок таләбе хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

«Зеленодол шәһәре эчке эшләр идарәсенең гражданнар мөрәҗәгатьләрен караганда законнарны үтәве турында» Татарстан Республикасы халык депутаты С.К.Осколок таләбенә җавапны игътибарга алырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 6 декабре
№ 2482

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 796. «Гражданнарны хәрби хезмәткә чагыруны Татарстан Республикасы территориясендә туктатып тору турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 15 сентябрендәге карарын үтәүнең барышы хакында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 23 сентябрендәге карарын үтәүнең барышы турында Татарстан Республикасы хәрби комиссары мәгълүматы хакында

Татарстан Республикасы комиссары Р.Ш.Мостаевның әлеге

мәсьәлә буенча мәгълүматын тыңлап һәм тикшереп, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы комиссары Р.Ш.Мостаевның мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы хәрби комиссары Р.Ш.Мостаевка Татарстан Республикасы территориясендә чакырылган һәм «кайнар нокталарда» һәлак булган хәрби хезмәткәрләрнең гаилә әгъзаларына законнарда каралган компенсацияләр түләүне тәэмин итү буенча тиешле чараларны күрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 6 декабре
№ 2483